وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№8 (229). Август / Шәүвәл – 1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




4-5 бит

## САБЫР ИТҮ ҺӘМ ТӘМУГ УТЫННАН КОТЫЛУ



7 бит

## *Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ:* "БЕР КҮРГӘН КЕШЕ КӨТЕП АЛА БУ САБАН ТУЕН!"



9 бит

## "ҺӘР ПОЧМАКТАН ТАТАРЛЫК АҢКЫП ТОРА"



10 бит

## БАЙЛЫКНЫ ДА ЧИСТАРТЫП ТОРЫРГА КИРӘК

## ИМАМНАР ФАТИХА АЛДЫ

Шушы көннәрдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин республиканың Әлки районына эшлекле сәфәр кылды. Районның 25 имам-хатыйбы мөфти кулыннан шушы вазифаларын башкарырга рөхсәт бирә торган шаһадәтнамә алды. Шулай ук ТҖ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе приказы нигезендә Исламетдин хәзрәт Шәйхетдинов 4 елга имаммөхтәсиб итеп расланды.



Утырышта ясаган чыгышында Татарстан мөфтие, район имамнарына мөрәҗәгать итеп, алга таба бергәләп хәрәкәт итәргә, ислам кыйммәтләрен активрак пропагандаларга, аеруча яшьләргә игътибарны арттырырга кирәк, дигән фикерен җиткерде. Эшчәнлекләре һәм традицион дини кыйммәтләрне торгызудагы тырышлыклары өчен мөфти хәзрәт имамнарга рәхмәт әйтте.

Әлки районына сәфәре кысаларында Камил хәзрәт Сәмигуллин район башлыгы Фердинат Дәүләтшин белән "Мәктәпкә әзерләнергә ярдәм ит!" хәйрия чарасында катнашты. Аннары Татарстан мөселманнары лидеры район башлыгы белән җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсеше һәм мөселман мәхәлләләре эшчәнлегенә бәйле кайбер мәсьәләләр турында сөйләште. Эш сәфәре азагында мөфти С.М.Лисенков исемендәге төбәк тарихы музеенда район тарихы һәм халыкның традицияләре белән танышты.



## ШАТЛЫКЛАРЫН УРТАКЛАШТЫЛАР

Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге ТҖ МДН делегациясе Түбән Новгород өлкәсенең Дзержинск шәһәрендә җамигъ мәчетен ачу тантанасында катнашты. Әлеге чарада баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, мөфтинең урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Батров һәм Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин катнашты, шулай ук төрле төбәк мөфтиләре һәм кунаклар да күп килгән иде.

Тантанада чыгыш ясап, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт җыелган халыкны иман йорты ачылу белән котлады. Мәчетләр төзелүнең мөһимлеге, бу эшкә өлеш кертүчеләрнең зур савап алуы хакында сөйләде. Аннары ул нәзарәт исеменнән Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдингә һәм Түбән Новгород мөфтие Гаяз хәзрәт Закировка "Хузур" нәшрият йорты чыгарган китапларны бүләк итте.

## ЯШЬЛӘР ӨММӘТКӘ ХЕЗМӘТ ИТӘЧӘК

Марий Элда Россия Мөселман яшьләре берлегенең бүлеге ачылды. Аны республиканың Красногорск бистәсе мәчете имам-хатыйбы Әмир хәзрәт Миннемуллин җитәкләячәк. Россия Мөселман яшьләре берлеге президенты Марсель Сабиров билгеләп үткәнчә, Марий Эл - мөселман яшьләре оешмасы үсеше өчен иң кулай төбәкләрнең берсе. Татарстанга якын урнашкан булуы да ике яклы хезмәттәшлек өчен бик уңайлы. "Без һәр әгъзасы үзенең рухи потенциалын ача һәм өммәткә файда китерә алырлык көчле оешма төзергә омтылабыз. Алга таба оешманың сайтын ачарга уйлыйбыз, барлык проектларыбыз һәм волонтерлар сафына керергә теләүчеләрнең анкеталары шунда урнаштырылачак", - дип белдерде Марсель Сабиров.

Күптән түгел Россия Мөселман яшьләре берлегенең бүлекләре Мәскәү, Коми Республикасы, Чувашстанда да ачылган иде.

## "МУНЧӘЛИ УКУЛАРЫ"ЫНДА СҮЗ ТӘРБИЯ ХАКЫНДА БАРДЫ

Чүпрәле районының Мунчәли авылында өченче мәртәбә "Мунчәли укулары" оештырылды. Быел әлеге чара балаларны дини гореф-гадәтләр белән тәрбияләүгә багышланды. Укуларда баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, Апанай мәчете имам-хатыйбы, нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз Сабиров, Тәтеш районы мөхтәсибе Инсаф хәзрәт Җәләлетдинов, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, тарих фәннәре докторы Наил Таиров һәм башка кунаклар катнашты.

Нияз хәзрәт чарага җыелучыларга, оештыручыларга мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен, рәхмәтләрен җиткерде. Хәзрәт күп гасырлык мирасыбызны барлауда, динебез кыйммәтләрен халыкка таратуда мондый чараларның мөһимлеген ассызыклады. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт исә авылларда дини гореф-гадәтләребезне, телебезне саклау хакында вәгазь сөйләде.

## ЭШЛЕКЛЕ ОЧРАШУЛАР, ФАЙДАЛЫ СӨЙЛӘШҮЛӘР

Август ае эшлекле очрашуларга бай булды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Россия Мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгат хәзрәт Таҗетдин һәм мөселман эшмәкәрләре белән очрашуы чәй табыны артында узды. Камил хәзрәт Сәмигуллин кунакларны Диния нәзарәтенең яңа проектлары һәм "Хузур" нәшрият йорты эшчәнлеге белән таныштырды. Очрашуда сүз меценатлыкны торгызуга кагылышлы мәсьәләләр хакында да барды.

***

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Әл-Мостафа (Иран, Кум) халыкара университетының Россиядәге вәкилләре белән дә очрашты. Университет вәкиле Хәмит Реза Сулки уку йорты хакында сөйләде. Аерым алганда, ул университетның хәнәфи мәзһәбе буенча белгечләр әзерләү юнәлеше, төрле телләр курслары турында мәгълүмат бирде. Ул мөфтине шәхсән уку йортына килеп, уку-укыту программалары белән университетта якыннан танышырга чакырды.

***

Кол Шәриф мәчетендә мөфти Камил хәзрәт Самигуллин Төркия Республикасының Казандагы генераль консулы белән очрашты. Очрашу Сабри Тунч Ангылының консуллык вәкаләтләре вакыты тәмамлану уңаеннан оештырылган иде. Татарстан мөфтие консулны Төркия Республикасында яңа президент сайлануы белән котлады һәм ТҖ МДН белән хезмәттәшлеге өчен рәхмәт белдерде. Үз чиратында Сабри Тунч Ангылы да мөфти Камил хәзрәткә рәхмәт әйтте һәм Төркия Республикасы белән Татарстан арасында багланышлар булдыруда нәзарәтнең өлеше зур булуын билгеләп үтте.

***

Татарстан мөфтие резиденциясенә Кырым Мөселманнары дини үзәге рәисе урынбасарлары Руслан Сәитвәлиев һәм Тимур Бакиев, үзәкнең пресс-секретаре Әнвәр Әхмәтов составындагы делегация килеп китте. Очрашу танышу характерында барды, кунаклар Кырым Мөселманнары дини үзәгенең эшчәнлеге турында сөйләделәр. Ике оешманың үзара хезмәттәшлеге һәм тәҗрибә уртаклашу мөмкинлеге турында да сүз булды.



## МӨСЕЛМАННАР ХАҖ СӘФӘРЕНӘ ҖЫЕНА

Ел саен 2 меңләп татарстанлы хаҗ сәфәре кылу нияте белән Мәккәгә һәм Мәдинәгә юл тота. Быелгы хаҗ кылу вакыты октябрьгә туры килә. Әлеге изге сәфәргә әзерлек кысаларында Татарстан таможня хезмәткәрләре "Казан" халыкара аэропортында тур-операторлар вәкилләре, изге сәфәрне кылучылар төркемнәре җитәкчеләре, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре белән очраштылар. Очрашу сәфәр кылучылар чикне узганда төрле кыенлыклар килеп чыкмасын өчен оештырылды. Шул нияттән таможня хезмәткәрләре таможня кагыйдәләре, чикләүләре хакында сөйләде. Татарстан таможнясы җитәкчесе вазифаларын башкаручы Максим Чмора игътибарны даруларга, экстремист эчтәлекле китапларга һәм сәүдә итү максатыннан алынган товарларга юнәлтте. Хаҗиларның сумкаларының вакытында тиешле урынга килеп җитмәү сәбәпләрен аңлатты. Бу хәл, нигездә, багаж авырлыгы тиешле дәрәҗәдән узып киткәндә килеп чыга, самолет экипажы багажның бер өлешен икенче рейска калдыра икән. Таможня вәкилләре сумкалар калган очракта нишләргә кирәклеген аңлатты.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре Татарстан таможнясына хаҗга әзерләнгәндә зур ярдәм күрсәтеп хезмәттәшлек итүләре өчен рәхмәт белдерде.

# ГЫЙБАДӘТНЕ АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ КУШКАНЧА БАШКАРУ ТИЕШЛЕ



**Бисмилләһир-рахмәнир рахим! Әссәләмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ! Мөхтәрәм дин кардәшләребез! Намаз - динебезнең терәге булган иң олы гыйбадәт. Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә намазны тиешле вакытларында үтәргә әмер бирә. Намаз вакытлары кояш йөрешенә бәйле. Безнең болгар бабаларыбыз ислам динен кабул итеп, шушы җирлектә намаз, ураза гыйбадәтен үтәгәннәр. Гыйбадәтләрне, шушы җирлекнең үзенчәлекләренә, авырлыкларына карамыйча, тиешенчә башкарып килгәннәр.**

Диния нәзарәтенә намазга кагылышлы бик күп мөрәҗәгатьләр булды. Ни өчен шәфәкъ кызыллыгы беткәнче ястү намазы укыла? Рамазан август-сентябрь айларына туры килгәндә, таң беленә башлауга карамастан, ураза тотучы кешеләр ни өчен сәхәр ашауны туктатмыйлар? Бу сораулар урынлы, чөнки моңарчы төзелгән календарь (ястү белән ахшам арасында сәгать ярым калдыру; сәхәргә ике сәгать калдыру билгеләнгән календарь) елның бөтен вакытына туры килеп бетми иде. Шуңа күрә хәзер Голәмалар шурасы яңа календарь төзегәндә, кояшның йөрешенә карап, астрономик исәпләүләргә таянып эш итте. Бу календарь ниндидер бер яңалык түгел, бездә инкыйлабка хәтле чыкканнары әнә шул рәвешле төзелгән.

Аныклап әйтәсе килә, бу календарьны төзегәндә иң беренче чиратта намаз вакытларын Аллаһы Тәгалә ничек кушкан һәм Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) ничек өйрәткән һәм галимнәребез дини китапларда ничек итеп аңлаткан булуына игътибар ителде. Ләкин без яшәгән җирлек географик яктан үзенчәлекле булу сәбәпле, җәй көннәрендә ястү намазының ахырын һәм иртәнге намазның башын астрономик исәпләү белән билгеләп булмый. Шуңа күрә безнең борынгы календарьларда иртәнге һәм ястү намазы вакытларын билгеләмәгәннәр, буш графа калдыра торган булганнар.

Ул вакыт Казан шәһәре өчен 5 нче майдан алып 8 нче августка кадәр дәвам итә. 9 нчы августтан без намаз вакытларын кире кояш йөрешенә карап билгеләргә мәҗбүр булабыз. Чөнки шәфәкъ кызыллыгы беленә башлау сәбәпле ястү вакыты керә. Һәм таң аклыгы беленә башлау сәбәпле иртәнге намаз вакыты керә. Менә шушы вакытта безнең календарьларда кисәк үзгәреш барлыкка килде, чөнки хисапка таянып ястү намазын 7 нче августта 22.05 тә укыган булсак, 8 нче августта ястү намазының чын вакыты керүе билгеле булу сәбәпле 23.05 тә укырга мәҗбүрбез. Һәм ураза тотарга теләгән кеше сәхәрне 01.17 минутта тәмамларга тиеш була. Ләкин бу вакыт тиз күчә, шуңа 15-20 көн эчендә ахшам белән ястү арасы без иярләнгән гадәти хәленә кайта.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу - зур сынау ул һәм анда кайбер мәшәкатьләр дә бар. Безнең бурычыбыз гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә бездән таләп иткәнчә, тиешле дәрәҗәдә башкару. Әгәр дә намаз билгеләнгән вакыты кергәнче башкарылса, ул нәфел намаздан китә, фарыздан китми. Шулай ук берәү таң атканны белә торып ашаса һәм шул килеш ураза тотса, аның уразасы кабул булмау ихтималы бар.

Кабатлап әйтәсем килә, яңа календарьны төзегәндә аның дини таләпләргә туры килүен күз алдында тоттык. Анда барлыкка килгән кайбер мәшәкатьләрне мөселман дин кардәшләребез аңларлар дип өметләнәбез. Чөнки инкыйлабка хәтле безнең бабаларыбыз шулай итеп гыйбадәт кылганнар һәм башкарганнар.

Аллаһ Раббыбыз кылган тырышлыкларыбызны кабул итсә иде, кулыбыздан килгәнчә җәмһүриятебез мөселманнары өчен файдалы эш-гамәлләр башкарырга насыйп әйләсен.

***Изге догалар белән, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

## ДӨНЬЯДА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР МӨСЕЛМАН ОНЛАЙН-ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ

*1-15 нче август көннәрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә Россия Мөселман яшьләре берлеге беренче тапкыр Мөселман онлайн-фестивале оештырды. Фестивальдә 30 га якын дин белгече катнашып, сөйләшүләрне 30 меңгә якын кеше тыңлады.*

Бу - башка фестивальләрдән аерылып торган чара булды: беренчедән, гадәти фестивальләрдә катнашучылар спикерларны сайлап алмый, ә бу очракта һәр тыңлаучы үзе теләгән спикерның чыгышын тыңлый алу мөмкинлегенә ия; икенчедән, анда катнашу өчен бары тик online-islam.ru сайтына кереп теркәлү узарга гына кирәк иде. Чыгышлар 15 көн телдә яңгырады, катнашучылар спикерларга алдан ук сораулар биреп куя алды, Россиянең һәм дөньяның танылган дин белгечләре белән аралашты, аларның вәгазьләрен тыңлады.

Фестивальнең беренче көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең эш бүлмәсеннән мөселман онлайн-фестивалендә катнашучылар белән аралашты. Ул бер сәгать дәвамында тыңлаучыларга коръәнхафиз булу серләре хакында сөйләде һәм сорауларга җавап бирде.

Катнашучы спикерларның географиясе гаять киң иде: Татарстан, Мәскәү, Украина, Беларусь, Төньяк Осетия, Австралия, Африка дәүләтләре. Фестивальдә дин әһелләре генә түгел, эшмәкәрләр, сәясәтчеләр, галимнәр, спортчылар, иҗат кешеләре дә лекцияләр укыды. Спикерларның чыгышлары яздырып барылып, тәрҗемә ителеп, online-islam.ru порталына эленәчәк. Димәк, теләге булган кеше докладларны үзенә җайлы вакытта кереп карый ала.

## МӘСЛӘГЕБЕЗ - БЕР, МАКСАТЫБЫЗ - УРТАК

**"Селигер-2014" Бөтенроссия яшьләр форумында быел илнең 85 төбәгеннән 4 мең кеше катнашты. "Казак яшьләре", "Россиянең рухи нигезләре", "Иҗтимагый берләшмәләр", "Хәрби-патриотик клублар", "Эшче яшьләр", "Рус хакыйкате", "Киләчәк китапханәчесе" һәм "Киләчәк укытучысы"-форумга килгән яшьләр әнә шундый сменаларга берләшеп эшләде. "Россиянең рухи нигезләре" сменасында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәре Гүзәл Идрис һәм мөселман җәмәгать эшлеклесе Ринат Нуриев та бар иде.**




"Без анда бик күп нәрсәгә өйрәндек, Россиянең башка төбәкләреннән, шәһәрләреннән килгән яшьләр белән танышып аралаштык, мәдәниятара, динара мәсьәләләр буенча диалоглар кордык, ислам диненә кагылышлы сорауларга җаваплар бирдек, хәйриячелек һәм дини эшчәнлектәге тәҗрибәбез белән уртаклаштык", - дип сөйләде Гүзәл Идрис форумнан алган тәэсирләре турында.

Россиянең рухи үсешен тәэмин итү максатында халыкларны берләштерү; актив максатчан яшьләрне зур көчле командага туплау; милләтара дошманлык тудырырга маташучыларга каршы тору юлларын эзләү; кешеләрне рухи-әхлакый кыйблага тарту һәм гражданлык хисләрен үстерүнең бердәм механизмын булдыру - Селигердагы "Гражданлык форумы"ның максаты әнә шулардан гыйбарәт.

Форумга олы кунаклар, шул исәптән дин әһелләре дә чакырылган. Башка дин вәкилләре үзләренчә гыйбадәт кылганда мөселманнар җәмәгать намазы укыган, ВДВның 31 нче бригадасында мулла вазифасын башкаручы Али хәзрәт Шәмсетдинов мөселман яшьләренә җомга вәгазе сөйләгән. Яшьләр атна дәвамында сәясәтчеләр, язучылар, эшмәкәрләр, журналистлар, педагоглар һәм дин әһелләре белән аралашкан. Махсус программаны үтеп, белем туплаганнан соң алар үзләренең проектларын яклаганнар. Түгәрәк өстәл артында тоталитар секталарга каршы закон проекты өстендә эшләгәннәр, кайбер законнарга төзәтмәләр кертергә тәкъдим иткәннәр. Соңыннан барлык бу тәкъдимнәр Иҗтимагый Палата әгъзаларына тапшырылган. Проектлар эшләгәндә храмнарны, тарихи һәйкәлләрне торгызу программасын тормышка ашыру, яшьләр арасында әхлак тәрбиясен үстерү, волонтерлар үзәге ачу буенча 20 ләп тәкъдим кертелгән.

Сменаны ачу тантанасына ЛДПР җитәкчесе В.Жириновский чакырылган. Спикер буларак нәфис гимнастика буенча Олимпия чемпионы Каролина Севастьянова; сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Николай Стариков, хәрби корреспондент Дмитрий Стешин, "Вольтер" газетасының баш редакторы Даниил Шишкин, "Краса России-2013" конкурсы җиңүчесе Анастасия Трусова чыгыш ясаган. Форумда катнашучылар проект менеджменты күнекмәләре һәм тематик чаралар уздыру буенча белем алган, шулай ук спикерлар аларга үзләренең уңыш серен дә чишкән.

# САБЫР ИТҮ ҺӘМ ТӘМУГ УТЫННАН КОТЫЛУ

**Исламда өметсезлеккә урын юк. Исламда теләсә нинди проблемага чара бар, шул исәптән өметсезлеккә дә. Аллаһ мөэминнәрнең өметсезлеккә бирелүен теләми. Өметсезлек - мөселманнарның иң зур дошманнарының берсе. Ләкин, кич ничек үтмәсен, барыбер көн туа, ә көн белән яңа таң ата.**

Өметсезлек мөселманның күңеленә үтеп керергә тиеш түгел, исламда өметсезлеккә, гомумән, урын юк. Әгәр сез шундый хәлгә тарысагыз - онытмагыз: караңгы төннәрдән соң якты көн туа, күңелләрне биләп алган болытлар барыбер кайчан да булса тарала.

Ибраһим пәйгамбәрнең (галәйһиссәлам) Аллаһка ялварган сүзләреннән уйланыйк: "Йә Раббым! Миңа тәкъва бала бүләк ит!"

Әйе, әгәр бала диндар, тәкъва булмаса, аның янындагыларга ул зур проблемага әверелә. Аллаһның бер тәкъва колы - Хозыр, Муса пәйгамбәр (галәйһиссәлам) белән булган вакыйгаларны искә төшерик. Бергә барганда, алар бер баланы очрата. Аллаһның тәкъва колы Хозыр бу баланы шунда ук үтерә. Муса пәйгамбәр (галәйһиссәлам) аннан: "Син ул баланы нигә үтердең?" - дип сорый. Хозыр аңа түбәндәгечә җавап бирә: "Бу малайга килгәндә, аның әтисе белән әнисе тәкъва мөэминнәр һәм без бу малайның итагатьсезлеге һәм көферлеге аларга зыян салыр дип курыктык һәм Раббыбыз бу бала урынына аларга күңеле белән сафрак һәм миһербанлырак икенче бер бала бирүен теләдек".

Димәк, нәрсәнең дә булса тамырлары яхшы булса, аннан үсеп чыккан үсентеләр дә яхшы була. Чәнечкеләр белән уратып алынган гөлчәчәк (роза чәчәге) - гаҗәеп бер күренеш. Кайвакыт, үсемлекнең кәүсәсе яхшы булып, аның ботак-үсентеләре начар булырга да мөмкин. Бу - Аллаһы Тәгаләнең капма-каршы булган әйберләрне, күренешләрне бергә урнаштыруы мөмкин икәнлеген дә күрсәтә.

Аллаһ сораганнарны кире какмый. Ибраһим (галәйһиссәлам) Аннан сораган һәм Аллаһ аңа тәкъва бала биргән.

"Муса әйтте: "Йә Рабби, күкрәгемне залимнәрнең каршылыгына сабыр итәргә киң кыл. Вә эшләремне миңа җиңел кыл. Вә телемнән төенне чиш, сөйләшүдә тотлыгуымны бетер. Тыңлаган кешеләр сүземне аңласын өчен (Муса сабый чагында авызына утлы күмер капкан, шул сәбәпле, тотлыгып сөйләшә торган булган). Миңа үз әһелемнән бер ярдәмче бир. Кардәшем Һарунны. Аның белән минем куәтемне яки арт тарафымны ныгыт. Вә аны пәйгамбәрлек эшемдә миңа ярдәмче иптәш кыл. Сиңа күп тәсбих әйтмәклегебез өчен. Вә Сине күп зикер итмәклегебез өчен. Тәхкыйк, Син безнең хәлләрне күреп беләсең" ("Та һа" сүрәсе, 20:25-35). Менә Аллаһы Тәгаләнең Мусага (галәйһиссәлам) җавабы: "Ий Муса! Тәхкыйк, сиңа сораган нәрсәләрең бирелде" ("Та һа" сүрәсе, 20:36).

Аллаһы Тәгаләгә догаларны кабул итү яки сораганнарны ирештерү ниндидер авыр эш яки проблема түгел. Коръәни-Кәримдә әйтелгән: "Безнең бар нәрсәне юктан бар итүебез - фәкать: "Бул!" - дип бер мәртәбә әйтүдер, күзне йомып ачкан арада ул бар булыр" ("Камәр (Ай)" сүрәсе, 54:50).

Аллаһка өмет баглаудан һәм Аңа ышанудан туктаган кеше - хак юлдан язган кеше. Кем дә булса үз байлыгына өмет тотса, бу - ышанычлы түгел, чөнки байлык кимергә дә мөмкин, кеше, гомумән, банкрот та була ала. Кем дә булса башка кешеләргә генә өмет итсә, ул кеше, гомумән, бернисез торып калырга мөмкин. Ә Аллаһка тапшырган, Аңа өмет баглаган кеше һәрвакыт өстенлекле хәлдә кала. Шуңа күрә, ярдәм кирәк булганда, Аллаһка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аллаһтан, фәкать бер Аллаһтан гына ярдәм сорарга.

Аллаһны онытып, ярдәмне башкадан сораган кешенең хәле шушы аятьтә күрсәтелгән кешеләрнеке кебек булачак: "Имансыз дин тотучыларның гамәлләренең мисалы, тигез киң җирдә рәшә (мираж) кебидер, бик сусаган кеше аны су дип белер һәм су эчәм дип барыр, хәтта барып җитсә - ул җирдә һичнәрсә тапмас, имансызның гамәле нәкъ шундыйдыр вә ул гамәле өстендә Аллаһның хөкемен табар, Аллаһ аңа тулысынча хисап ясап, тиешле җәзаны бирер. Бит Аллаһ бик тиз хисап итүчедер" ("Нур" сүрәсе, 24:39). Димәк, Аллаһтан түгел, башкадан сорасалар, ул кешеләр бу гамәлләре белән Аллаһның ризалыгына каршы килә, кешенең каршында мираждан башка берни дә булмый һәм ул кешеләргә Аллаһ каршында хисап тотарга туры киләчәк. Беркем дә беркемгә, үз акчаларына һәм үз акылына гына ышанып бетмәсен. Нур - Аллаһ нуры гына, булган бар нур да Аллаһтан гына, Кодрәт - Аллаһ кодрәте генә, булган бар кодрәт тә Аллаһтан гына, бар Бөеклек тә - Аллаһтан гына. Аллаһ кына бар мактауларга да лаеклы. Бары Аллаһтан гына куркырга кирәк. Әгәр дә бу шулай булса, әйдәгез, болай дип әйтик: "Лә иләәәһә илләллаһ". - "Аллаһтан башка илаһ юк". Әгәр нидер кирәк булса, фәкать Аллаһтан гына сорыйк.

Ибраһим пәйгамбәргә (галәйһиссәлам) сиксән яшь булганда, ул Аллаһтан угыл сораган һәм Аллаһ аның бу соравын канәгатьләндермәгәнмени? Пәйгамбәр угыл сораганда күрәзәчеләргә барганмы, әллә нинди дә булса берәр юраучыга мөрәҗәгать иткәнме?

Ул Аллаһка мөрәҗәгать иткән, Ул Үз Кодрәте белән бар билгесезлекләрнең ачкычларын да Үз контролендә тота. Ибраһим пәйгамбәрнең (галәйһиссәлам) Аллаһка ялваруының нәтиҗәсе ни соң? Аңа итагатьле угыл бүләк ителгән. Ул угылның кем икәнлеге сезгә билгелеме? Ул угыл Исмәгыйль (галәйһиссәлам) булган.

> *"Өметсезлек мөселманның күңеленә үтеп керергә тиеш түгел, исламда өметсезлеккә, гомумән, урын юк. Әгәр сез шундый хәлгә тарысагыз - онытмагыз: караңгы төннәрдән соң якты көн туа, күңелләрне биләп алган болытлар барыбер кайчан да булса тарала"*

Әйдәгез, бу турыда Коръәни-Кәримдә ни әйтелгәнен карап китик: "Ул бала җиде яшенә җитеп атасы илә йөри башлагач, Ибраһим әйтте: "Ий углым, мин төшемдә Аллаһ тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерыламын, уйлый күр, син бу эшкә ничек карыйсың?" Углы Исмәгыйль әйтте: "Ий атам, ни белән боерылган булсаң, шуны эшлә, мин Аллаһ хөкеменә ризамын, бу эштә мине, Аллаһ теләсә, сабыр итүчеләрдән табарсың" ("Саффат (Сафта торучылар)" сүрәсе, 37:102).

Аллаһ бу баланы киң күңелле, тәкъва һәм сабыр итеп тасвир итә. Ул чынлыкта да шундый кеше булган. Йә Аллаһ, безнең балаларыбызны да шундыйлардан, киң күңеллеләрдән, тәкъвалардан һәм сабырлардан әйлә! Нинди гүзәл Хаким, Нинди гүзәл Ярдәмче Син, Аллаһ!

Ибраһим пәйгамбәргә (галәйһиссәлам) туксан тугыз яшь тулгач, аның хатыны Сара үзләренең балалары булуын тели башлый. Бу ни өчен мөмкин булмасын, Хаҗәр Сараның колы булган бит. Аллаһ сабырларның савапларын киметмәс. Әйдәгез, бу турыда изге хәдистә ни әйтелгәнен карап китик: "Мин тәне, байлыгы, гаиләсе, балалары белән сынау ителгән һәм ул сынауларны зур сабырлык белән кичергән колларымнан хисап алырга кыенсынам, аның урынына Мин аларга Җәннәттә урын бирермен".

Коръәни-Кәримдә әйтелгән: "...Сабыр итүчеләргә хисапсыз әҗерләр бирелер" ("Зүмәра (Халык төркеме)" сүрәсе, 39:10).

Шулай итеп, Ибраһим пәйгамбәргә (галәйһиссәлам) туксан тугыз яшь булган, ә аның хатыны Сарага - сиксән биш. Сара бик тә үзләренең балалары булуын теләгән. Ибраһим (галәйһиссәлам) кунаклар кабул итәргә яраткан. Ул өендә бар нәрсәне дә кунаклар алдына куя торган булган. Бервакыт, өч көн буена аларның ишеген беркем дә шакымаган. Шуннан соң Ибраһим пәйгамбәр (галәйһиссәлам) болай дигән: "Йә Аллаһ, түзәр хәлем калмады, миңа нинди дә булса берәр кунак юлласаң иде!" Шул сүзләрне әйткәч, аның ишеген шакыганнар. Ул ишеген ачкан. Алар бер кунак көтсә, килүчеләр - өч кеше булган. Аларның кулларында, аякларында, башларында һәм башка җирләрендә тузан бөртеге дә, яки юлдан килүгә бернинди ишарәт тә булмаган. Алар кемнәр булган һәм ни өчен килгән соң? Бу сорауга җавапны Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Тәхкыйк, безнең илче фәрештәләребез бала белән сөенеч бирмәк өчен Ибраһим галәйһиссәламгә килеп сәлам бирде. Ибраһим: "Сезгә дә сәлам булсын", - диде. Озын-озакка сузмыйча, Ибраһим майда пешергән бозау итен кунаклар алдына алып килде" ("Һуд" сүрәсе, 11:69).

Аятьнең башында "сәламан" - "тынычлык" сүзе кулланылган, ә аннары - "сәламун" сүзе. Беренче җөмлә үз структурасы белән фигыль җөмлә булып тора, ә икенчесе - исем җөмлә. Исем җөмлә фигыль җөмләдән көчлерәк. Ә бу исә, Ибраһим пәйгамбәрнең (галәйһиссәлам) сәлам җиткерүе - кунакларның сәлам җиткерүенә караганда көчлерәк һәм гүзәлрәк булуы турында сөйли.

Аннары Ибраһим пәйгамбәр (галәйһиссәлам), эчкә үтеп, кунакларга пешкән бозау ите алып килгән. Гомумән, аларга берничә килограмм ит тә җиткән булыр иде, тик юмарт кеше, кемне дә булса сыйларга теләсә, чаманы белми, кирәгеннән күбрәк сый чыгарып куя. Ләкин кунаклар Ибраһим (галәйһиссәлам) алып килгән, яңа гына пешкән бу тәмле ризыкка кагылмаган. Пәйгамбәр (галәйһиссәлам) шикләнеп куйган, борчылган, ләкин моны сиздермәгән. Тәкъдим ителгән бу ризыкка кагылмаган кунаклар кемнәр булган соң?

"Фәрештәләр әйтте: "Син бездән курыкма, без сиңа шатлыклы хәбәр китердек, сездән бер галим бала туачак"" ("Хиҗер" сүрәсе, 15:53). Әйе, фәрештәләр аңа әйткән: "Без, фәрештәләр - Раббыңның илчеләре".

Фәрештәләр ашамый, эчми, йокламый, өйләнми һәм үрчеми, аларның арасында ир яисә хатын җенесе юк. Фәрештәләрнең миссиясе нидән гыйбарәт соң? Аларның иң беренче вазыйфалары - Аллаһны мактау. Алар моны армый-талмый башкара. Коръәни-Кәримдә әйтелгән: "Кичә вә көндез Аллаһны мактап тәсбих әйтерләр, алар һич тә арымас" ("Пәйгамбәрләр" сүрәсе, 21:20). Аларның мактаулары безнең тын алуыбыз кебек. Ий кеше туганым, әгәр син минутына уналты тапкыр гына тын алсаң да, фәрештәләр үз мактауларын өч тапкыр тизрәк әйтә: "Бар кимчелекләрдән дә азат Аллаһка дан! Аллаһка - бар мактауларыбыз, Аллаһтан башка илаһ юк, Аллаһ - Әкбәр (Бөек)". Аллаһның Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) әйткән: "Фәрештәләрнең тын алуларыннан һәм аларның авырлыгыннан Күкләр ыңгырашты".

Әгәр, фәрештәләрнең кайсының -



сәҗдә, кайсының рөкүгъ кылуын, анда басып торырга урын да булмавын исәпкә алганда, Күкләрнең ыңгырашуы - нормаль күренеш. Бар фәрештәләр дә Аллаһ Рәсүлен (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) Мигъраҗ төнендә елмаеп каршы алган, ләкин алар арасында бер фәрештә булган, ул елмаймаган да, көлмәгән дә. Аллаһның Рәсүле (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) үзенең юлдашы Җәбраил фәрештәдән:

"Бер дә елмаймаган бу фәрештә кем ул?" - дип сораган. Җәбраил аңа: "Елмаймаган фәрештә - Тәмуг капкаларын саклаучы фәрештә. Кыямәт көнендә Тәмугка баручылар шул фәрештәгә: "Ий капкаларны саклаучы, Аллаһ безнең җаныбызны алсын да, безне коткарсын", - дип әйтер. Аллаһның Рәсүле (саллэллаһу галәйһи вәсәлләм): "Ә син шул фәрештәнең аларга кайчан җавап бирәчәген беләсеңме?" - дип сораган. Җәбраил аңа болай дип җавап биргән: "Бер ел вакыт үткәч бу фәрештә аларга болай дип җавап бирер: "Сез шунда калырсыз. Сезгә бит хак дин - хакыйкать ирештерелгән иде, тик сезнең күбегез аны танымады".

Мөхтәрәм җәмәгать! Инде төп темабызга әйләнеп кайтыйк. Ибраһим пәйгамбәргә (галәйһиссәлам) кунаклар сыйфатында килгән фәрештәләр аңарга киң күңелле тәкъва улы булачагы турында сөенечле хәбәр китергән. Пәйгамбәрнең (галәйһиссәлам) хатыны, моны ишетеп, бик шатланган, ә аннары гаҗәпләнеп сораган: "Ул баланы мин табачакмынмы? Мин карт бит инде, бала табарга сәләтсез". Фәрештәләр аңа: "Аллаһның гамәлләренә гаҗәпләнергә кирәкме? Нишләп син Аллаһ эшләренә шулкадәр гаҗәпләнәсең?" - дигәннәр. Коръәнне шәрехләүче кайбер мөфәссир (бер нәрсәне аңлатып бирүче - Ред.) галимнәр шулай дип аңлатма бирә: "Сиксән биш яшьлек хатынның шунда ук күреме килә башлаган".

Аллаһы Тәгалә нәрсәгә дә булса: "Бул!" - дип әйтсә, ул шунда ук була. Шуңа да Ибраһим пәйгамбәрнең (галәйһиссәлам) күпме вакытлар үткәч улы туууына бер дә гаҗәпләнергә кирәкми. Монда шикшөбһәгә урын калмаска тиеш. Коръәни-Кәримдә бу турыда болай диелгән: "Фәрештәләр әйтте: "Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә гаҗәпләнәсезме? Ий, пәйгамбәрлек заһир булган өй кешеләре! Сезгә Аллаһның рәхмәте вә бәрәкәте булачак. Ул - Аллаһ эшләгән эшләрендә мактаулырга тиешле булган бик олуг бер зат" ("Һуд" сүрәсе, 11:73).

Күп еллар баласызлыгыннан соң, Сара Исхак исемле ул тудырган. Исмәгыйль белән Исхак - бертуган. Ул - Ибраһим (галәйһиссәлам) бик картайгач туган. Аллаһның ихтыярында була алмаган эш юк.

Хәтта бернинди дә өмет калмады дигәндә дә Аллаһы Тәгалә теләсә - теләгәнен бирә ала. Моны һәрвакыт истә тотарга кирәк.

Ибраһим пәйгамбәр (галәйһиссәлам) рәхмәтсез кеше булмаган. Ул, башка пәйгамбәрләр кебек үк, кимчелекләрдән азат булган. Сөенечле хәбәр алгач, ул Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтен һәм мактауларын ирештергән: "Карт көнемдә миңа Исмәгыйль вә Исхакны бирүче Аллаһы Тәгаләгә барча мактау! Тәхкыйк, Раббым догаларны ишетүче вә кабул итүче. Йә Рабби, минем үземне һәм балаларымны намазларны үтәүче кыл, ий Раббыбыз, догаларыбызны кабул кыл! Ий Раббыбыз, үземне вә ата-анамны һәм барча мөэминнәрне ярлыка, Кыямәт көнендә хур итмә!"

Аллаһның Рәсүле (саллэллаһу галәйһи вәсәлләм) бервакыт болай дигән:

"Минем өммәтемә каза килгәндә ул аның белән очрашыр". Аннан: "Андый каза кайчан булыр?" - дип сорагач, ул: "Хакимнәр, көч һәм шәфкатьсезлек кулланып, үз гражданнарының мөлкәтен тартып ала башлагач", - дигән.

> *"Аллаһка өмет баглаудан һәм Аңа ышанудан туктаган кеше - хак юлдан язган кеше. Кем дә булса үз байлыгына өмет тотса, бу - ышанычлы түгел, чөнки байлык кимергә дә мөмкин, кеше, гомумән, банкрот та була ала. Кем дә булса башка кешеләргә генә өмет итсә, ул кеше, гомумән, бернисез торып калырга мөмкин"*

Ни генә булмасын, башкаларныкы булганны үзләштерергә, узурпацияләргә (законсыз, көч кулланып яулап алырга) куркытып, янап алырга ярамый. Тормышны һәм милекне яклау - исламда иң төп принципларның берсе. Башка кешеләрнең җирен тартып алырга беркемнең дә хакы юк. Аллаһның Рәсүле (саллэллаһу галәйһи вәсәлләм) әйткән: "Бер кушин җир узурпацияләгән кешегә Кыямәт көнендә җитмеш тапкыр күбрәк йөкләтелер".

Кызганыч, хәзерге вакытта кайбер кешеләр, акчага хирыслыклары аркасында, күп кенә тыелган эшләргә "тыелган" итеп карамый. Ничек итеп булса да, акчаны кулга төшерү өчен, алар ялган вәгъдәләр бирә. Ялган вәгъдә кебек гөнаһның кәффарәте (гөнаһтан арыну гамәле) бар дип уйласалар, алар ялгыша. Андый гөнаһ каршында аның кәффарәте - тау янындагы бер кырмыска кебек кенә. Кечкенә генә бер кырмыска бик зур бер тауны урыныннан күчерә аламы? Юк, күчерә алмый. Ялган вәгъдәне "гамус" дип атыйлар, ул шул вәгъдәне биргән кешене турыдан-туры тәмуг утына илтә.

Кызганыч ки, хәзер ялган вәгъдәләр тау елгалары кебек ага. Кешеләрдә Аллаһтан курку да, оят та калмады. Йә Аллаһ, безнең вафатыбызны, аннан соңгы тормышыбызны да яхшылардан әйлә.

Гайсә пәйгамбәр (галәйһиссәлам) белән булган бер вакыйганы сөйләп китик. Гайсә пәйгамбәр (галәйһиссәлам), Мәрьям улы, урам буенча барганда үзенең юньсез эшен эшләп йөргән бер бурны (каракны) очраткан. Ул аңа болай дигән: "Ий туган, син нигә урлашасың?" Ләкин бу бур: "Юк, Аллаһ белән ант итәм, мин берни дә урламадым", - дигән. Бөекләрнең берсе исемене лаек булган бу пәйгамбәр, беләсезме, нәрсә дигән? Ул: "Аллаһ дөресен әйткән, димәк, минем күзләрем мине алдаган". Гайсә пәйгамбәр (галәйһиссәлам), Аллаһ исеме белән ителгән ант аркасында, нәкъ менә шулай дип әйтергә мәҗбүр булган. Ләкин хәзерге кешеләр Аллаһы Тәгалә исемен бик еш куллана башлады, алар кирәк булса да, кирәк булмаса да Аллаһны искә ала, бик еш Аның исеме белән вәгъдә бирә, ант итә. Бу вакытта аларның күбесе үз өсләренә нинди зур җаваплылык алганнарын аңлап та бетерми.

Бервакыт Малик ибне Динар, Басра урамнары буйлап йөргәндә, егылып яткан бер исерекне тап булган. Исерткеч катыш төкерекгә аның авызыннан ага, ә ул үзе яткан җиреннән: "Аллаһ, Аллаһ", - дип кычкырып ята икән.

Малик: "Мин бу кешенең авызын булса да юыйм әле, Аллаһ исемен чиста авызы белән әйтсен", - дип уйлаган. Ул шулай эшләгән дә, барып аның авызын юган, аннары аны үзенең өенә алып кайткан. Төнлә, йоклаган чакта, ул төш күргән, төшендә бер тавыш ишеткән: "Малик, син Минем хакка бу кешенең авызын чистарттың, ә Мин синең хакка бу кешенең күңелен пакьләдем". Шул вакытта Малик, дулкынланып, уяныл киткән. Иртәнге намазга азан әйтәләр икән. Ул торган, тәһарәт алган һәм намаз укырга мәчеткә киткән. Мәчеткә баргач, ул шундый күренешкә тап булган: ниндидер бер кеше, мәчет янына килеп, Аллаһка ялвара икән: "Йә Аллаһ! Менә мин Синең каршыңда торам һәм, мине ярлыкавыңны сорап, Сиңа ялварам. Кума мине бу капкадан. Син минем тәүбәмне кабул итәсеңме? Әйт, миңа җиңелрәк булыр. Әгәр дә минем тәүбәмне кабул итсәң, миңа белгерт, мин үз-үземне кулга алырмын, яхшы якка үзгәрермен һәм Сиңа гыйбадәт кылырмын".

Малик ибне Динар аннан: "Аллаһ сине кызганырлык кем син ул хәтле?" - дип сораган. "Мин - кичә син Аллаһ хакына авызын юган шул эчкече кешемен. Күргәнеңчә, Аллаһ мине туры юлга бастырды һәм минем хәзерге урынымны сиңа да күрсәтте", - дигән теге кеше.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйткән: "Минем мөэмин бәндәләремә әйт: "Ий бәндәләрем, гөнаһ кылып үзегезгә зарар иткән булсагыз, Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә Аллаһ гөнаһларны ярлыкаучы, Ул - Аллаһ - ярлыкаучы вә рәхимледер" ("Зүмәра (Халык төркеме)" сүрәсе, 39:53).

Аллаһның Рәсүле (саллэллаһу галәйһи вәсәлләм) мөбарәк хәдисләренең берсендә әйткән: "Зәкят - күтәрә алмаслык авырлык кебек - бик җаваплы йөк". Ел саен үз байлыгыңның кырыктан берен мохтаҗларга бирергә кирәк, кешеләргә бу бик авыр йөк булып тоела. Ләкин, Аллаһы Тәгалә изге хәдисләренең берсендә әйткән: "Колым (минем), син башкалар өчен сарыф ит, ә Мин синең өчен сарыф итәрмен".

Җитеш, бай тормыш белән яшәгән кешеләр, зәкят түләмәс өчен, мең төрле сәбәп таба, әмма, шул ук вакытта, алар Аллаһ тыйган күп әйберләргә аннан да күбрәк суммада акчаларын сарыф итә. Шул ук изге хәдистә Аллаһы Тәгалә әйткән: "Ышанып тапшырылган әйбер - әманәт байлыкка әйләнгән вакытта..." Мәсәлән, син, кемгәдер киләсең дә, әйтәсең: "Мин килгәнче шушы әйберне саклап тор әле". Ул сиңа: "Юк, без туганнар да, дуслар да, диндәшләр дә түгел. Мин аны саклауга алып кала алмыйм", - ди. Яки, киресенчә, син кемгә дә булса, нинди дә булса бер әйбереңне саклауга калдырасың, әйләнеп кайткач, барып аннан ул әйберне сорыйсың, ә ул сиңа: "Аллаһтан курык, син миңа берни дә калдырмадың", - ди. Син аңа:

"Ә мин сине судка бирәм", - дисең. Ул сиңа: "Кая теләсәң - шунда бар, судта җиде ишек, кайсысына керәсең килсә, шунысына кер дә, исбатлап кара", - дип җавап биреп, сине куып җибәрә. Беләсезме, Кыямәт көнендә бу кешегә Аллаһ ни дип әйтәчәк? Ул аңа: "Хәзер инде хуҗасына аның мөлкәтен кире кайтар", - диячәк. Ул кеше әйтер: "Ий Аллаһ, Ул дөнья инде тәмам булды, хәзер - икенче дөнья. Аңа бирәсемне мин хәзер каян алыйм инде?" Шунда Аллаһ фәрештәләргә әйтер: "Аны тәмуг чокырларының берсенә ташлагыз!" Фәрештәләр аны тәмугка ташлар һәм әйтер: "Әнә шул чокырның төбенә кара!" Ул кеше тәмуг төбендәге шул чокырга карар һәм аның төбендә аңа ышанып тапшырылган шул әйберне күрер. Шуннан ары аңа әйтерләр: "Хәзер инде син шунда төш тә, аны алып килеп хуҗасына бир!" Бу кеше тәмуг төбендәге шул чокыр төбенә таба барыр, аңа анда барып җитәр өчен генә дә җитмеш ел вакыт кирәк булыр. Кайберләре, гомумән, анда барып та җитә алмас. Шуңа күрә дә кешеләр арасындагы милек мәсьәләләрендә Аллаһы Тәгаләдән куркырга кирәк. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә игътибарлы булырга кирәк.

Тагын бер тарихи хәл белән танышып узыйк. Бер сәүдәгәр вафат булган. Ул гомере буе намазын калдырмаган, уразасын җиренә җиткереп тоткан, зәкятен түләгән, хаҗ да кылган булган. Вафатыннан соң бер дусты аны төшендә күргән һәм аннан сораган: "Син Аллаһ белән очрашкач, Аның каршындагы дәрәҗәң ничек булды? Синең белән анда ничек мөгамәлә иттеләр?" Ул кеше әйткән: "Аллаһ мине җәзага тартты". Дусты, аптырап, аннан сораган: "Син бит намазыңны да вакытында укып бардың, уразаңны да тиешенчә тоттың, зәкят тә бирдең, хаҗ да кылдың. Нигә сине җәзага тарттылар соң?" Аның бу соравына әлеге кеше болай дип әйткән: "Аллаһ миңа сораулар бирде, ә мин Аның сорауларына җавап таба алмадым. Ул миннән: "Ни өчен син товарыңны үлчәгәндә кадәр үлчәүләреңнең төгәллеген көйләмәдең?" - дип сорады. Бу мәсьәләгә шул рәвешчә җентекләп карау минем башыма да килми иде".

Ә хәзер өйләребез янындагы базарларга карыйк. Анда кемдер алдаша, кемдер урлаша, кемдер ялганлый, ә кемдер талый. Ә бит Аллаһы Тәгалә әйткән: "Кем караклык кыла - ул кеше безнең беребез түгел". Үлчәүләрдә алдаган каракларга карагыз. Аллаһы Тәгалә алар турында менә нәрсә ди: "Киметеп үлчәүчеләргә үкенеч - каты газаптыр. Алар башка кешеләрдән берәр нәрсә үлчәп алса, үлчәүне тутырып, мул үлчәп ала. Башка кешеләргә савыт яки бизмән белән үлчәп биргәндә, киметеп үлчиләр. Әйә, ул кешеләр Олуг Кыямәт көнендә терелеп кубарылачакларын уйламыйлармы? Ул көндә кешеләр барча галәмне тәрбия итүче Аллаһ хозурында хисап өчен басып торыр" ("Мутаффифин (Киметүчеләр)" сүрәсе, 83:1-6).

Кадерле мөселманнар! Аллаһ Рәсүленең (саллаллаһу галәйһи вәсәлләм) Әбү Һурайра исемле сахабәсе (радыйаллаһу ганһү) сөткә су өстәгән бер кешене күргән һәм аңа болай дигән: "Раббың сиңа сөттән суны киредән аерып бирергә кушкач, син Аңа ни дип җавап бирерсең? Син Аңа нәрсә дип җавап бирә аласың?" Йә Аллаһ! Безне Сиңа илтүче туры юлдан аерма! Рәхим-шәфкатеңнән аерып, безне берүзебезне генә калдырма! Безне Синдә генә, бары тик Синдә генә мохтаҗлыкта әйлә!

***Татарстан***
***Республикасы мөфтие***
***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

# ФӘРЕШТӘЛӘРГӘ ЫШАНУ

***Иманның икенче баганасы - Аллаһының фәрештәләренә ышану. Аллаһы Тәгаләгә табынган кеше Аның фәрештәләренә дә ышана.***

Мөселман үзенең сизү әгъзаларының мөмкинлекләре чикләнгән булуын нык белергә тиеш. Без нәрсәне дә булса күрмибез, ишетмибез яки тоймыйбыз икән, бу нәрсә дөньяда юк дигән сүз түгел әле. Аллаһы яраткан затлар бер-берсеннән үзләренең табигатьләре белән аерылалар. Фәрештәләр кеше сизү әгъзалары ярдәмендә төшенә алмаган затлардан санала. Ләкин без аларга мәҗбүри ышанырга тиеш, чөнки Аллаһы Тәгалә фәрештәләрнең булуы турында безгә Коръәни-Кәримдә үк хәбәр иткән, ә Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вәсәлләм фәрештәләр турында хәдисләрендә әйтеп калдырган.

Фәрештәләр нурдан яралтылган. Алар ашамый да, эчми дә, җенесләре дә юк һәм һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә табынып яши. Кешеләрдән аермалы буларак, фәрештәләр беркайчан да гөнаһ кылмыйлар һәм Аллаһының кушканнарын һәрвакыт тиешенчә үтиләр.

Һәр фәрештәнең үзенең аерым вазыйфасы бар. Аллаһы Тәгаләнең төп фәрештәләренең исемнәре һәм вазыйфалары:

Җәбраил - иң төп фәрештә, аның аша Аллаһы Тәгалә пәйгамбәр галәйһиссәламнәргә хәбәр җибәрә;

Микаил - яңгыр, кар, җил һәм башка шундый табигать күренешләре өчен җаваплы фәрештә;

Исрафил - Кыямәт көне җитүен һәм үлгәннәрнең кабаттан терелүен белгертеп, Сур мөгезенә өрәчәк фәрештә;

Газраил - кеше үлгәндә аның җанын алучы үлем фәрештәсе;

Мөнкир һәм Нәнкир - кешедән кабердә аның дине турында сорау алачак фәрештәләр.

Моннан тыш, һәр кешенең яхшы һәм яман гамәлләрен язып баручы фәрештәләре бар. Әгәр кеше үзенең гаебен гамәл дәфтәренә язып куелганчы танып өлгерсә, аның гөнаһысы ярлыканачак һәм гамәл дәфтәренә язылмаячак. Мөселман үзенең янында фәрештәләр булуын һәм аларның кеше гамәлләрен язып баруларын, һәр эш-гамәле өчен җавап тотачагын һәрвакыт истә тотарга тиеш.

Һәр фәрештәнең үз вазыйфасы бар, дидек. Ләкин Аллаһы Тәгаләгә фәрештәләр кеше җанын алу, кабердә сорау алу яки кешенең гамәлләрен язып бару өчен генә кирәк дигән сүз түгел. Аллаһы Тәгалә беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Шулай да, Ул бу дөньяны нәкъ шул рәвешле яралткан һәм Аның һәр карарында камил акыл тоемлана.

***"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән***

# ДӨНЬЯДА ЯШӘРГӘ ГЫЙЛЕМ КИРӘК...

Кадерле дин кардәшләребез! Менә тагын сентябрь аена керәбез. Күпләрегез баласыноныгын мәктәп-мәдрәсәгә әзерләү, уку әсбаплары юнәтү кебек күңелле мәшәкатьләр белән мәшгульдер. Хәерле, уңышлы уку еллары булсын!

Күңелле мәшәкатьләр, дибез, чөнки безнең халык гомергомергә укымышлы булган, белемгә тартылган. Тарихының иң болгавыр елларында да, бераз матди мөмкинлеге килеп чыкса (йә булмаса мәхәллә белән җыелышып), сәләтлерәк баласын, туганын, авылдашын ерак җирләргә гыйлем эстәргә җибәргән... Бер гыйбрәт вә үрнәк итеп, сезнең игътибарыгызга элекке Бөгелмә өязе Миңлебай авылы мулласы Гыйльман хәзрәт Кәриминең улы Фатыйхка (күренекле язучы, нәшир, журналист, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Кәрими - Ред.) язган мәшһүр хатын тәкъдим итәбез.

*"Углым! Мин сине кеше булырга, гыйлем алыр өчен ерак җирләргә җибәрәм. Киләчәктә милләткә файдалы булуыңны телим, сине җибәрүем байлыгым артыктан түгел. Синнән башка биш балам һәм карт атам бар. Шуларның өлешеннән аерып сине озатам. Дөньяда яшәргә гыйлем, төзек әхлак, тырышлык кирәк. Бер сәгать гомереңне бушка үткәрмә. Анда да "ишаннар", "суфилар" күп булыр. Кеше сүзенә алданып, алар тирәсенә сырышма. Андыйлардан файда күрә алмассың. Онытма: укырга, өйрәнергә ялкауланма. Ялкау булган кеше тереләр арасында йөрүче мәет кеби. Тик кабергә күмелми. Уку яшендә әхлагыңны бозсаң, тәгълим итүдән читтә калсаң, синең өчен һәртөрле бәланең башыңа килүен истә тот. Җанымны фида итәрлек дәрәҗәдә тырышып алган намусымны каралтырлык хәрәкәттә булма. Ялкау һәм начар иптәшләр белән аралашуыңны ишетсәм, миннән бертөрле ярдәм, мәрхәмәт көтмә. Атаң-анаңның синең өчен бөтен көчләрен кызганмый иткән хезмәтләренә каршы эштә булсаң, көфране нигъмәт булыр. Безне шатландырырлык, киләчәктә илгә йолдыз төсле якты биреп торырлык угыл булып кайтуыңны телибез.*

***Гыйльман Ибраһим углы. Миңлебай, 1892 сәнә.***

*Хатыма өстәмә итеп шуны да языйм. Төркиянең гали мәктәбен яхшы итеп бетереп, имтихан бирсәң, бәлки Яурупаның берәр мәмләкәтенә барып гыйлем алырга теләрсең, Германиягә яки Франциягә, үзең уйлап безгә язарсың. Минемчә, әгәр һөнәр-техник эшләре белән кызыксынсаң, Германиягә, әгәр матур күренеш, әдәбият, көтебханәләр белән кызыксынсаң - Парижга барып, күбрәк чит телләрне яхшы белеп кайтуың тиеш булыр дип уйлыйм. Сиңа вәгъдә биргәнемчә расходлык барыр".*



# СҮЗЛӘРЕҢ КАЛЕБТӘН ЧЫКСЫН...

***Әбү Һүрайра тапшырган хәдистә пәйгамбәребез әйтә: "Аллаһы Тәгаләгә, җавабына ныклап ышанган хәлдә, дога кылыгыз һәм белеп торыгыз: Аллаһ гафил күңелдән чыккан һәм игътибарсыз кылынган доганы кабул итми" (Тирмизи риваяте).***

Догаңны кылганда, Аллаһка әллә нинди изге сүзләр әйтсәң дә, әгәр ул сүзләрең йөрәгең аша үтмәсә, аларның файдасы юк. Дога кылганда калебнең гафил булуы доганың тәэсирен һәм куәтен юкка чыгара.

Бик күп кешеләр доганың әйтелешенә, матур сүзләренә игътибар биреп, аның эчтәлеген онытып җибәрәләр. Доганы сихерчеләрнең тылсымлы сүзләре, сихри сүзтезмәләре кебек аңларга ярамый. Доганың бөтен хикмәте бәндәнең эчкерсез күңел белән Раббысыннан нәрсә сораганын аңлап, чын йөрәктән соравына кайта. Берәүнең әллә нинди матур гыйбарәләр, шигъри юллар белән сораганы күңеле аша үтми икән, ул сүзләрнең кыйммәте булмас. Ә сүзгә осталыгы булмаган кеше, тегеннән-моннан гына җыйган сүз белән, әмма күңелен биреп дога кылса - ул кабул булыр...

***Йосыф ДӘҮЛӘТШИН, Тәбән Кама районы имам-мөхтәсибе***



### ЭРЕНЛЕ ШЕШ ЧЫГУГА КАРШЫ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

*Риваять буенча, Аллаһ Рәсүле (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) хатыннардан Зәйнәп бинте Җәхштән: "Синең яныңдагы шифалы үлән, күз үләне, сөрмә һәм яран үләне бармы?" - дип сорады. Зәйнәп, әйе, диде. Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) үләнне алды да аны ике аяк бармагы арасындагы чуанга куеп, болай диде: "Аллаһуммә мотфи әль-кәбир үә мөкәббир ас-сагыйр атфиэһа ганни" (Аллаһым! Син зур нәрсәләрне кечерәйтәсең, кечкенә нәрсәләрне зурайтасың. Аның (чуанның) утын сүндер, миннән китәр). (Әхмәд ибне Хәнбәл: 5/370).*

## ҺӘР МӨСЕЛМАН БЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ НӘРСӘЛӘР

- Аллаһка шөкер, без - мөселманнар.
- Безнең илаһыбыз - Аллаһ, Китабыбыз - Коръән, кыйблабыз - Кәгъбә, Пәйгамбәребез - Мөхәммәд Мостафа саллəллаһу галәйһиссәлам.
- Беренче кеше һәм беренче пәйгамбәр - Адәм галәйһиссәлам.
- Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) әтисенең исеме - Абдуллаһ, бабасының исеме - Абдулмоталлиб, әнисенең исеме - Әминә.
- Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) 50 яшенә кадәр гомер иткән хатынының исеме - Хәдичә.
- Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) дүрт кызы һәм өч улы булган. Кызлары - Зәйнәп, Рукиййа, Өммегөлсем, Фатыйма. Уллары - Ибраһим, Касыйм, Абдуллаһ.
- Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) 40 яшендә пәйгамбәрлек килә башлаган. Коръән аңа 23 ел дәвамында иңгән. Ул Мәдинә шәһәрендә 63 яшендә вафат булган.
- Коръәндә 25 пәйгамбәрнең исеме бар.
- Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) 571 нче елны Мәккә шәһәрендә дөньяга килгән. 622 нче елны Мәдинәгә һиҗрәт кылган (күчкән). 632 нче елны Мәдинәдә вафат булган.
- Аллаһтан кешеләргә тапшырылган тагын өч китап бар: Муса галәйһиссәламгә җибәрелгән Тәүрат, Дауд галәйһиссәламгә җибәрелгән Забур, Гайсә галәйһиссәламгә җибәрелгән Инҗил.
- Елда 5 мөбарәк кичә бар. Бу кичәләрдә күп итеп гыйбадәт кылырга, Аллаһыдан гөнаһларны ярлыкавын сорарга һәм тәсбих намазы укырга кирәк. Ул кичәләр болардыр:

***Мәүлид ән-Нәби*** - рабигыльәүвәл аеның уникенче кичәсе таңында Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) дөньяга килгән;

***Рәгаиб кичәсе*** - рәҗәп аеның беренче җомгасы, Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) әти-әнисе кавышкан көн;

***Мигъраҗ кичәсе*** - рәҗәп аеның 27 нче кичәсе. Бу кичәдә Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) күккә ашкан;

***Бәраәт кичәсе*** - шәгъбан аеның 25 нче кичәсе, кыйбла үзгәртелгән көн. Бу кичәдә бер ел эчендә булачак эшләр хакында хөкем кылына, әҗәл вә гомерләр билгеләнә;

***Кадер кичәсе*** рамазан аеның соңгы ункөнлегенә яшерелгән. Бу кичәдә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд Мостафа саллəллаһу галәйһи вәсәлләмне Пәйгамбәр итеп сайлый; Изге Коръән иңә башлый.

## Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ:

# "БЕР КҮРГӘН КЕШЕ КӨТЕП АЛА БУ САБАН ТУЕН!"

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Балтач районы мөхтәсибәте бергәләп уздырган республикакүләм балалар Сабан туе Татарстанның күренекле дин әһелләрен, җәмәгать һәм сәнгать эшлеклеләрен бер мәйданга җыйды. Алар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Батров, Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм район мөхтәсибләре бар иде. Сабан туенда йөзләгән бала төрле-төрле уеннарда ярышты, табигать кочагында ял итте, дин әһелләре нәсыйхәтләрен ишетте.**



**ТАТАРСТАННЫҢ** баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев инде менә җиде ел рәттән шушы Сабан туен оештыруда үзе башлап йөри.

- Дини бәйрәмнәрнең асылын аңлату ниятеннән үткәрелгән балалар Сабан туеның беренчесе Балтачта булды. Икенче елны Карадуганда уздырдык. Аннан безнең авылны - Бөрбашны сайладык. Максатыбыз - ел саен бер авылда уздыру иде. Соңыннан имамнар белән фикерләштек тә, Бөрбашта төпләнергә карар кылдык. Безнең авылдагы дини тормышны өйрәнеп китү өчен башкаларга бер форсат та әле бу, - ди Җәлил хәзрәт.

Ә өйрәнерлек нәрсәләр, чыннан да, күп монда. Инде менә ничә еллар мәчет белән мәктәп коллективы кулга-кул тотынышып эшли. Бөтен республикада (бәлки, Россиядәдер) беренчеләрдән булып Бөрбашта һәм Балтач районының башка мәктәпләрендә әхлак дәресләре укытыла башлады. Балалар өчен мөселманча Сабан туе да бары тик биредә генә үткәрелә...

- Бәйрәмнең Гает тәкбирләре әйтеп башланып китүе дә күп нәрсә хакында сөйли, - ди Татарстан мөфтие урынбасары, Казанның Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин. - Моны Сабан туе гына дип атау дөрес түгелдер, балалар өчен Гает бәйрәме дип әйтү урынлыдыр, чөнки биредә балалар җитезлектә, тапкырлыкта гына көч сынашып калмыйлар, дини яктан да әзерлекләрен күрсәтәләр.

Әлеге чараның географиясе елдан-ел киңәя бара. Алдагы елларда Киров өлкәсеннән, Марий Эл, Чувашия Республикаларыннан килгән булсалар, хәзер Башкортстаннан, Ульяновскидан да кунаклар өстәлгән. "Бер күргән кеше көтеп ала бу Сабан туен. Төп авырлык мәктәп коллективы өстенә төште инде, мин иганәчеләрне табучы гына", - дип тыйнаклык күрсәтсә дә, иганәчеләренең ниндиләрен тапкан әле Җәлил хәзрәт: 300 мең сумнан артык акчаны бүләк алырга гына тотканнар; 150 кг дөге, 120 кг ит, 180 кг кишердән 10ар чиләкле 6 казан тэлеңне йотарлык пылау пешергәннәр. Узган ел әнә көрәштә җиңүчегә скутер бирергә ниятләгәч, дүрт иганәче





вәгъдә иткән булган, берсен генә алганнар. Башкаларын соңрак бирерсез дидем, ди хәзрәт. Сүзләрендә торганнар: быелгы баш батыр Балтач районы Чепья авылы егете Илназ Миңнемуллин да скутерлы булды.

Бәйрәмгә бик күп кунаклар кайткан иде. Россия Дәүләт Думасы депутаты Фатих Сибагатуллин белән Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Хашимова, бәйрәмне киңрәк масштабта үткәрергә кирәк, дигән фикерләрен җиткерделәр. Танылган журналист Әлмира Әдиятуллина исә: "Бу - безнең Татарстаныбызның дәрәҗәсен күтәрә, татарларны берләштерә, мөселманнарны җыйный, әдәп-әхлагыбызны камилләштерә торган чара. Карап, күзәтеп утырдым: монда милли моң, ислам диненең кыйммәте, нигезе ачык чагыла. Менә шуларны бала күңеленә кечкенәдән сеңдерәбез икән, милләтебезнең киләчәге булачак", - дип хисләре белән уртаклашты.

Өйлә намазы вакыты керүгә ярышлар тукталды. Ир-атлар, хатын-кызлар аерым, мәйданны тутырып намаз укыды. Әлегә намазга басмаганнар аларны читтән күзәтеп, сокланып утырды.

- Җырчы буларак Сабан туеның төрлесендә катнаштым, - ди танылган җырчы, Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов. - Ислам йолалары буенча оештырылган бу чараны бөтен республикага җәелдерергә кирәк. Мәйданны махсус күзәтеп чыктым, тәмәке пыскыткан бер кешене очратмадым, агач төбенә утырып аракы эчүче юк. Һәркем ислам кушканча киенеп килгән. Биредәге тәрбияви мохит мине нык уйландырды.

Фердинанд Сәлахов бу көнне үзе дә балачагына кайткандай булды, ахры. Мәйдан тулы балаларның төрле ярышларда катнашканын күзәткәннән соң, җырчы түзмәде, яшел чирәм өстенә яланаяк чыгып, рәхәтләнеп җырлады.

- Балтач районында яшәүчеләр бик бәхетле икән, - ди Россия һәм Татарстан мөслимәләре берлеге рәисе Наилә ханым Җиһаншина. - Җәлил хәзрәт халыкны бер йодрыкка туплап тора. Имамны халык хөрмәт итмәсә, гади генә бер авылга бу кадәр кунак килмәс иде. Без, гадәттә, бәйрәмнәрне өлкәннәр өчен уздырабыз. Ә биредә, киресенчә, балалар өчен әллә нинди конкурслар, чаралар уйлап тапканнар. Бала белән бергә әти-әни, әби-бабай да килә. Гаиләне рухи яктан баетучы бәйрәм бу.

Өлкәннәр өчен дә уеннар оештырылган иде. "Ат"лар чабышында әниләр балаларын күтәреп чапты, әтиләр "машина" йөртте, муллалар әтәч куды. Әтәче генә бик хәйләкәр булып чыкты, имамнарны мәйдан тирәли әллә ничә тапкыр әйләндерде. Ахырдан түзмәде, бирелергә мәҗбүр булды...

***Лилия НУРМӨХӘММӘТОВА***

# ГЫЙЛЕМ АЛУДА КЕМ АЛДА?

**Менә тагын яңа уку елы якынлаша. Тиздән меңнәгән шәкертләребез мәдрәсә ишекләрен ачып керер, мәчет каршындагы курсларда яңа укулар башланыр. Бу өлкәдә нинди уңышларга ирешкәнбез, эшләнәсе эшләребез күпме? Нәрсәгә игътибар итәргә кирәк? Бүгенге сәхифәдә, статистика мәгълүматларына таянып, әнә шул сорауларга җавап эзләрбез.**

Башлангыч белем бирү системасы мөселман мәгарифенең бик мөһим өлеше, чөнки мәчет каршындагы курсларда балалар гына түгел, өлкәннәр дә беренче дини гыйлемнәрен ала. Мондый курслар Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәтенең урыннардагы дини оешмалары тарафыннан оештырыла. Курсларны тәмамлаучыларга бернинди дә документлар тапшырылмый, чөнки бу - ислам буенча ликбезлар гына. Әмма хикмәт документта түгел, мәчет каршындагы курсларда укучылар санының елдан-ел арта баруы үзе үк моңа дәлил. Узган уку елында республика буенча, мәсәлән, 13-14 мең кеше башлангыч дини белем алды. Татарстанда мәчетләр санының 1500 дән артып китүен исәпкә алганда, укулар аларның яртысыннан күбрәгендә алып барыла дигән сүз. Алдынгылар исемлеген Арча мөхтәсибәте җитәкли, бүгенге көндә анда 1325 кеше мәчет каршындагы курсларда башлангыч белем ала.

Башлангыч белем бирү системасында укучыларның составы да бик төрле. Статистика мәгълүматларына караганда, белем алучыларның 70 проценты - хатын-кызлар. Мәктәп яшендәгеләр (7 яшьтән 18 яшькәчә) - 10-15 процентны, пенсия яшендәгеләр 35 процентны тәшкил итә. Укучыларның яртысыннан күбрәге - 25 тән 50 яшькәчә булган ир-атлар һәм хатын-кызлар.

Мәчет каршындагы курсларда укытучы мөгаллим-мөгаллимәләрнең составында да төрлелек сизелә. Узган уку елында, мәсәлән, шушы курсларда 800-850 ләп укытучы белем бирде. Шуларның 30-34 проценты - имамнар, ә 66 проценты урта яки югары дини белеме булган, яисә шундый ук мәчет каршындагы курсларда башлангыч белем алган укытучылар иде. Тагын шуны да әйтеп узасы килә: башлангыч курс укытучылары арасында югары гуманитар белеме булганнар байтак.

Статистика мәгълүматлары кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Беренчедән, укучылар саны елдан-ел арта бара. Татарстан буенча 2008-2009 нчы уку елында аларның саны 5-6 меңләп булса, 2011-2012 нче уку елына 11 меңгә җиткән. Әмма әзерлекле яшь кадрлар саны әлләни күп түгел әле. Республиканың эре шәһәрләрендә бу артык сизелми, ә менә үзәктән ерак районнарда һәм авылларда укытучыларга кытлык бар. Бу юнәлештә Диния нәзарәте актив эшчәнлек алып бара. Яшь имамнарга грантлар бирү, укучылар арасында конкурслар һәм викториналар уздырып, аларның белем дәрәҗәләрен тикшереп тору шул максатларны күздә тотып башкарыла.

*Айдар КАРИБУЛЛИН,*
*ТҖ МДНнең фән һәм мәгариф бүлеге баш белгече*

## КАЗЫЯТЛӘР

***ТӨНЬЯК КАЗЫЯТЕ*** - Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба, Теләче мөхтәсибәтләре;
***БАШКАЛА*** - Казан мөхтәсибәте;
***ТӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ*** - Югары Ослан, Биектау, Яшел Үзән, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе;
***КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ*** - Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш;
***КӨНЬЯК*** - Аксубай, Алексеевск, Әлки, Яңа Чишмә, Спас, Чистай;
***КӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШ*** - Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Нурлат, Чирмешән, Ютазы;
***КӨНЬЯК*** - Азнакай, Әлмәт, Зәй, Мөслим, Сарман;
***ТӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШ*** - Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Мамадыш, Менделеев, Минзәлә;
***КАМА БУЕ ТӨБӘГЕ*** -Чаллы, Түбән Кама, Тукай мөхтәсибәтләре.

### Мәхәлләләр саны




### Курслар саны




### Укучылар саны




### Укучыларның гомуми саны



# "ҺӘР ПОЧМАКТАН ТАТАРЛЫК АҢКЫП ТОРА"

**Иске татар бистәсендә, Каюм Насыйри урамында урнашкан Апанай мәчете - Казанның иң матур мәчетләренең берсе. Ул 1768-1769 нчы елларда эшмәкәр Ягъкуб Солтангалиев тарафыннан төзелгән.**





Узган гасырның утызынчы елларына кадәр мәчетнең ишекләре ябылып тормаган: Аллаһ сүзен җиткереп, аң-белем таратып, татарларны туплап торган ул. Манарасын җимереп, өстәмә өченче кат төзеп, совет чорында аны балалар бакчасы итеп файдаланганнар. Илдә саф җилләр исә башлагач, 1995 нче елда, ниһаять, иман йорты мәхәллә мөселманнарына кайтарылды. Шул ук елны реставрация эшләре башланып, 2011 нче елда ишекләре кабат ачылды. Аны төзекләндерүгә танылган дин әһеле мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов зур тырышлык куйды, республика җитәкчелегенең, аерым кешеләрнең хәйрия ярдәме дә зур булды. Шәһәребезнең күрке булган бу мәчет Федераль әһәмияттәге архитектура һәйкәлләре исемлегенә кертелгән. 2013 нче елның азагында Татарстан мөселманнары арасында билгеле дин әһеле, Диния нәзарәтенең дәгъват бүлеге җитәкчесе **Нияз хәзрәт САБИРОВ** мәчеткә имам-хатыйб итеп билгеләнде.

Апанай мәчетендә минем беренче генә булуым түгел, килгән саен күңелдә шатлык, бәйрәм рухы тоям. "Бу сүзләрне башкалардан да ишеткәнем бар, - ди хәзрәт. - Шулай булуы гаҗәп тә түгел: бу бит тарих, монда һәр почмактан татарлык аңкып тора..." Баскычның сырлы-бизәкле култыксаларына тотынып, өске катка күтәреләм, намаз уку залларын тагын бер кат карап чыгам. Әнә шул татарлыкны сакларга тырышканнар биредә: бизәлеш, төсләр, хәтта тәрәз төбендәге яран гөлләренә хәтле үзебезчә, саф татарча...

Лагерьга 20 ләп кыз бала йөри икән. Дәресләренә кереп, аларның сабак алганнарын да тыңлап утырдым. Кызларны "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе мөгаллимәләре, шәкертләре укыта, тәрбия кыла. Ислам дине нигезләреннән тыш кызлар халкыбызның тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнәләр, музейларга йөриләр, мәшһүр шәхесләребез белән очрашулар уздыралар. Кыз бала бит инде ул булачак хуҗабикә дә, шуны күздә тотып, алар өчен тегүчеләр әзерли торган көллияттә осталык дәресләре оештырырга ниятләп торалар... Хәзрәт сөйләгәннәрне тыңлап утырдым-утырдым да, үзем дә сизмәстән, бу кызларга кызыгып, бигрәк бәхетлеләр инде, Казаныбызның тарихи үзәгендә яшәгәч, менә шушы тарихи мәчеткә йөри алалар, дип әйтә куйдым. "Безгә хәтта Җиңү проспектыннан да киләләр, менә шунысы сөендерә дә инде, димәк, мәчетебезне беләләр", - диде хәзрәт, җавап итеп.

Июнь аенда монда малайлар лагере эшләгән. Соңыннан әти-әниләрен чакырып, уларның нәрсәгә өйрәнгәннәрен күрсәткәч, әй сөенгәннәр инде. Рамазан аенда унлап малай Коръән уку курсларына йөргән. Мин килгән көнне дә берничә бала намаз уку залында, укытучылары - коръәнхафиз Исахан Бабиев тирәсенә тезелешеп, Коръән укып утыралар иде. Бу курслар дәвамлы булачак икән. Ә сентябрь аеннан, Аллаһка тапшырып, мәчет каршында ислам дине нигезләре, Коръән уку курслары ачып, беренче уку елын башлап җибәрергә җыеналар. Һәр чәршәмбе һәм якшәмбе көннәрендә икенде намазыннан соң укыла торган лекцияләр дә дәвам иттереләчәк, аларны Диния нәзарәтенең дәгъват бүлеге белгечләре Тимергали хәзрәт Юлдашев белән Гали хәзрәт Ибодов алып бара. Берничә китап авторы, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров үзе дә лекцияләр укырга нияте барлыгын сиздерде.

Менә шундый күңелле мәшәкатьләр, уй-ниятләр белән яшәп яталар Апанай мәчете мәхәлләсендә.

***Нәүбәһар КӘБИРОВА***









# БАЙЛЫКНЫ ДА ЧИСТАРТЫП ТОРЫРГА КИРӘК

БАЙЛЫКНЫ ДА ЧИСТАРТЫП ТОРЫРГА КИРӘК

## НӘРСӘ УЛ ЗӘКЯТ?

**Зәкят ул** - мал-мөлкәттән (байлыктан) фәкыйрьләр, мохтаҗлар өчен бирелә торган билгеле бер күләмдәге акча. "Зәкят" сүзе "чистарту" дип тәрҗемә ителә. Чөнки, беренчедән, зәкят - кешеләрнең байлыгын мал-мөлкәт туплау белән бәйле хаталардан һәм ялгышлыклардан, ярамаган эшләрдән арындыра. Икенчедән, ул кешеләрнең күңелләрен саранлык һәм шәфкатьсезлек кебек сыйфатлардан азат итә, зәкят нәтиҗәсендә кешеләр юмартракка һәм мәрхәмәтлерәккә әйләнә. Өченчедән, зәкят - Аллаһ ризалыгы өчен үз ният һәм гамәлләреңне пакьләү, чөнки зәкят түләгән кеше, ният һәм гамәлләренә Аллаһы Тәгаләнең контроле барлыгын тоя һәм Аның кануннары буенча яши башлый. Дүртенчедән, зәкят җәмгыятьне социаль тигезсезлек аркасында килеп чыга торган канәгатьсезлектән арындыра. Бишенчедән, хәлле кешеләр дә авыр вакытларында аларны ярдәмсез калдырмаячакларын аңлый.

Ирекле, балигъ, үз акылында булган һәм үзенең бу бурычы бар икәнен белүче һәр мөэмин-мөселман зәкят түләргә тиеш.

## ЗӘКЯТ ТҮЛӘҮНЕҢ ШАРТЛАРЫ

**Беренче шарт.** Ел дәвамында билгеле бер мөлкәткә, акча суммасына (нисабка) ия булу. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) болай дигән: "Ел тәмам булганчы берниндн мөлкәттән дә зәкят алынмыйдыр" (Әбү Дауд). Зәкят ел азагына булган суммадан чыгып түләнә, ягъни зәкят түләү өчен кешенең ел азагына без алда әйтеп киткән нисабка ия булуы шарт.

**Икенче шарт.** Зәкят кешегә үзенең көндәлек тормышын тәэмин итәр өчен кирәк булган акчадан (мөлкәттән) алынмый. Монда азык-төлек, ул кешеләрне яшәгән йортлары, өй җиһазлары, аларны суык һәм эсседән саклаучы киемнәре, эш кораллары, акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр өчен аларның бу эшләрендә кулланылучы китаплары һәм көндәлек тормыш өчен зарур булган башка әйберләр күздә тотыла.

**Өченче шарт.** Зәкят түләүче кешенең тиешле ниятке булу, бу ниятнең зәкят түләү өчен акчалар бүленгән вакытта булуы.

**Зәкятне нинди мөлкәттән түлиләр?**

Зәкят җиде әйбердән түләнә: алтын-көмеш, сәүдә, җиләк-җимеш һәм яшелчә, маллар (мөгезле эре терлек һәм мөгезле вак терлек), файдалы казылмалар, табылган хәзинәдән.

**Кыйммәтле кәгазьләрдән зәкят түләнәме?**

Әлбәттә, алтын, көмеш һәм акчадан түләнгәндәге кебек үк 2,5 процент күләмендә түләнә.

**Нинди суммадан башлап зәкят түләнә башлый?**

Зәкят түли башлауның минималь микъдары, ягъни, нисабны акчалата бәяләү алтынның дөньядагы хакына бәйле. Ул микъдар 84 грамм алтын хакына бәрабәр. Без 84 грамм алтынны аның бәясенә тапкырлыйбыз да, шул 84 грамм алтын хакын, ягъни шуңа бәйле рәвештә, нисабның суммасын ачыклыйбыз. Әгәр дә кешенең алтыны, көмеше, кыйммәтле кәгазьләре, әйләнештәге товарларының күләме нисабтан артык икән, ул бар бу мөлкәте суммасының 2,5 процентын зәкят итеп түләргә тиеш.

**Зәкят түләүнең вакыт кысалары бармы?**

Зәкят ел саен түләнеп торырга тиеш. Әгәр дә кешенең мөлкәте нисабтан артып китә икән, һәм бер ел вакыт үткәннән соң да аның мөлкәте нисабтан ким булмаса, ул үзендә булган мөлкәт суммасыннан зәкят түли.

## ЗӘКЯТТӘН КЕРГӘН АКЧАЛАР НИНДИ МАКСАТЛАРДА ТОТЫЛА?

**Зәкятнең кемнәр өчен тотылуы Коръәндә билгеләнгән: "Садакалар - фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга вә зәкят өчен исламга күңелләре өлфәт хасыйл иткән кешеләргә: тоткында булган кешеләргә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, ислам дине өчен Аллаһ юлына һәм малсыз калган мосафирларгадыр, шул күрсәтелгән урыннарга бирмәк Аллаһыдан фарыз ителде. Аллаһ белүче вә хөкем итүче"** ***("Тәүбә" сүрәсе, 60 нчы аять).***

**Ярлылар.** Әбү Хәнифәнең фикере буенча, ярлылар исәбенә үзендә нисаб күләмендә акча булмаган яки үзенең бу акчаларын (мөлкәтен) үзенең көндәлек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен (үзен торак, кием һ.б. белән тәэмин итәр өчен) тотучылар керә. Әгәр дә кеше



нисаб күләмендәге финанс чараларына (мөлкәткә) ия икән - ул ярлы булып исәпләнә, әмма зәкяттән ярдәм ала алмый.

**Мөлкәтсез кеше** - бер нәрсәсе дә булмаган кеше.

Зәкят җыючылар - зәкят җыю һәм аны бүлеп бирү белән шөгыльләнүче кешеләр, алар бу эшкә мөселманнар тарафыннан билгеләнеп куела. Зәкят җыю һәм җыелган ул сумманы бүлеп бирү - кешеләр алдында да, Аллаһы Тәгалә алдында да зур җаваплылыкка ия.

**Бурычлылар.** Болар үз мәнфәгатьләрендә, мәсәлән, кием сатып алырга, дәваланырга һ.б. яки башкалар мәнфәгатьләрендә, мәсәлән, алар арасындагы дошманлыкка чик куяр өчен, бурычка акча алып торган кешеләр. Үзләре үз бурычларын үз көчләре белән түли алмаган кешеләрнең бурычлары зәкят исәбенә капланырга мөмкин. Ләкин бу шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән максатларда алынган бурычларга гына кагыла. Үз көче белән бурычын кайтара алырга сәләтле кеше зәкят итеп җыелган суммалар ярдәменә исәп тота алмый.

**Аллаһ исеме өчен булган эшләргә** исламга өндәү һәм дәгъвәт кылу, аның фәнни потенциалын ныгыту һәм мөселманнар арасында фетнә чыгара торган каршы як идея һөҗүмнәрен кире кайтару буенча эшчәнлек керә. Зәкят акчалары мөселман гыйбадәтханәләре һәм уку йортларын тоту өчен дә кулланылырга мөмкин.

Мосафирлар. Зәкят акчалары юлда булучы һәм бу вакытта авыр хәлдә калган (мәсәлән, бар акчаларын да югалтып бетергән, талануга дучар булган) мосафирларга ярдәм итү өчен кулланыла. Бу вакытта аларның гомуми матди хәле исәпкә алынмый.

## ЗӘКЯТ ӨЧЕН ТӘГАЕНЛӘНГӘН АКЧАНЫ МӘЧЕТ ЯКИ МӘДРӘСӘЛӘРГӘ КИТЕРЕРГӘ ЯРЫЙМЫ?

Фикыһ буенча элекке китапларда зәкят акчасы мәчетләргә бирелергә тиеш түгел дип күрсәтелә иде. Ул вакытларда (бу китаплар язылган мөселман илләрендә) зәкятне казнага җыю белән дәүләт үзе шөгыльләнә иде. Ил җитәкчесе моны үзе тикшереп тора, бу юнәлештә эшләүче тулы бер структура бар иде. Мәктәп һәм мәдрәсәләрне тоту чыгымнарын дәүләт үзе күтәрергә тиеш иде. Шуңа күрә дә элек бу мәсьәлә күтәрелми иде. Ә хәзер исә вәзгыять бөтенләй башкача. Без мәчет һәм мәдрәсәләр төзибез, ә дәүләт, кызганычка, аларны тоту буенча акча бирми. Бүген без йөргән мәчетләр, безгә имамнар әзерләп чыгаручы мәдрәсәләр яшәү чыганакларын үзләре эзләргә мәҗбүрләр. Ә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, мәсәлән, гади бер мәэзин дә аена 850 доллар хезмәт хакы ала. Төркиядә бар мәчетләр дә дәүләт исәбенә тотыла, ә аларның имамнары Ислам эшләре һәм вәкыф министрлыгы фәрманы белән тәгаенләнә.

XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында безнең мәчет-мәдрәсәләребезне дә хәйриячеләр һәм төрле дәрәҗәдәге сәүдәгәрләр тоткан. Бу турыда мәчетләрнең исемнәре дә сөйли: Борнай мәчете, Апанай, Гали мәчетләре. Ул эшмәкәрләр игелекле эш эшләгәннәр, проблеманың асылын бик яхшы аңлаганнар. Беркем дә, бүгенге көндә кем дә булса үз акчасына мәчет яки мәдрәсә тотарга тиеш, дип әйтми. Мәчет һәм мәдрәсәләрнең эшчәнлекләрен тәэмин итү - бар мөселманнарның җаваплылыгында! Белүебезчә, зәкят Аллаһ юлында йөрүчеләр өчен түләнә, ә мәчет һәм мәдрәсәләр нәкъ менә Аллаһ диненең торгызылуы һәм таралыш алуына хезмәт итә. Һәм шунысын да әйтеп китәргә кирәк, без үген горурлана торган татар зыялыларының барысы да диярлек шундый мәдрәсәләрдә белем алганнар.

## НИ ӨЧЕН МӨСЕЛМАННАР ЗӘКЯТ ТҮЛӘҮДӘ СҮЛПӘНЛЕК КҮРСӘТӘ?

**Беренчедән**, зәкятне түләү иманның никадәр нык булуына бәйле, ә безнең иманнарыбыз дөньявилык мәшәкатьләре белән буталган. Без бу дөнья тормышын киләчәк ахирәт тормышыбыздан ныграк яратабыз. Җилле машиналар алырга, шәп йортлар төзеп калырга, байлыкларыбызда бер-беребез белән ярышырга тырышабыз. Моның бер гаебе дә юк, Аллаһ акча эшләүне тыймый, Ул исраф итүчеләрне һәм зәкят түләмәүчеләрне генә яратмый. Гомумән, зәкят түләү - безгә бай булып яшәргә тәкъдир язган өчен Раббыбызга рәхмәтебез ул. Аның биргән бар бәрәкәтенә шөкер итеп, мөлкәтенең 2,5 проценты Раббыныкы икәнлеге турында уйланмау - кешенең Раббыга күрсәткән иң зур рәхмәтсезлеге. Аллаһ барыбер аларны үзенә кайтарачак, чөнки алар ул кешенең үз милке түгел. Кеше, Аллаһ сакласын, төрле бәла-казаларга, авыруларга, һәлакәтләргә, банкротлыкка тарырга мөмкин, чөнки безнең тормышыбыз сынаулардан тора. Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) болай дигән: "Аллаһ барлык бай мөселманнарга да зәкят бирергә күрсәтмә биргән. Әгәр дә бай мөселманнар моны эшләмәсәләр, ярлыларның мохтаҗлык вакытында кичергән һәр җәфасы байлар җилкәсенә ятар. Чөнки алар зәкят түләмәгәннәр. Хисап көнендә алар ул ярлылар кичергән бәла-казалар һәм җәфа чигүләр өчен җавап бирерләр һәм Аллаһ аларны бу гамәлләре өчен каты җавапка тартыр" (Сахих Мөслим). Бу аларның үзләренеке булмаган мөлкәт белән файдаланганнары, фәкыйрьләргә тиешле булган байлыклары аларга бирмәгәннәре өчен эшләнер.

**Икенчедән**, бу пассивлык күпләрнең зәкят түләүне мәҗбүри эш дип исәпләмәвендә чагыла. Алар аны түләве мәҗбүри булмаган садакалар белән бутыйлар.

**Өченчедән**, мөселманнар дингә реаль өлеш кертә алуларын тоймыйлар, бу эшне алар өчен башкалар эшләргә тиеш дип уйлыйлар.

**Дүртенчедән**, акча ул ачык күренеп торган әйбер, ә саваб - Аллаһның бүләге исә ачык күренеп тормый. Һәм без, мөселманнар, Аллаһның безгә исәпләгән савабын тоярга өйрәнә алмадык әле. Әгәр дә мәчеткә һәр килгән саен 50 доллар акча вәгъдә итсәләр, безнең мәчетләребезгә, мөгаен, халык сыя да алмас иде.

**Бишенчедән**, мөселманнар зәкят түләү белән аларның байлыклары кимер дип уйлыйлар, гәрчә Коръән һәм Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) сөннәте, киресенчә, зәкят түләүнең безнең байлыкны арттыруын күрсәтсә дә. "Аллаһ юлына биргән малның мисалы - бер бөртек орлык кеби, ул орлык үстерде җиде башак, һәр башакта йөзәр орлык. Аллаһ үзе теләгән бәндәсенә җиде йөздән дә арттырып бирер. Аллаһ киңлек иясе һәм барча нәрсәне белүчедер" ("Бәкара" (Сыер) сүрәсе, 261 нче аять). "Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) әйткән: "Бәндәнең тәгамы зәкят түләүдән кимемәс" (Сахих Мөслим).

Әгәр дә халык зәкят түләүдән туктаса, ул яңгырдан һәм Аллаһ рәхмәтеннән мәхрүм ителер. Җирдә җанварлар һәм башка мәхлуклар булмаса, Аллаһ анда беркайчан да яңгыр яудырмас иде.

Әгәр дә байлыктан зәкят түләнми икән, бу байлык үз-үзен бетерә башлаячак.

Түләнми калган зәкят Хисап көнендә богаулар рәвешендә булыр, ул богаулар зәкят түләмәгән кешене богаулап алырлар.

Хисап кылу вакытында зәкят түләмәгән кешеләрнең маңгайларына, ян якларына һәм аркаларына келәймә сугарлар.

Күңелләрнең һәм байлыкның чисталыгы бурычларны тәгәл үтәүдән гыйбарәт. Ә байлыкка ия булуның бурычы - аннан вакытында һәм тиешенчә зәкят түләү.

# ШИКЛӘНСӘҢ - АШАМА

***Кибет киштәләре төрле тәм-томнардан сыгылып торса да, мөселман сатып алучысына шактый кыенга туры килә. Чөнки ризык составына кушылган юк кына берәр өстәмә синең хәләл дигән ризыгыңны хәрәмгә чыгарырга мөмкин. Димәк, кәрзинеңә салганчы ризыкның ялтыравыклы кабына язылганнарны җентекләп укырга кирәк. Химик, биолог яки азык-төлек сәнәгате белгече булмаса да, кайбер нәрсәләрне һәр мөселман белергә бурычлы. Эшне, нәрсә ул хәләл, дигән сорауга җавап эзләүдән башлыйк.***

Аллаһы сүбхәәнәһү вә Тәгалә Изге Коръәндә: "Ий, кешеләр! Җирдә булган пакь, хәләл ризыкларны гына ашагыз! Вә шайтан эзенә кермәгез, ул сезгә ачык дошман!"("Әл-Бәкара", 168 нче аять), - дип хәләлнең ни икәнен аңлатып бирде. Ерткыч җанвар, үләксә һәм дуңгыз итеннән тыш, шәригать кануннары буенча чалынган пар тояклылар һәм кош итеннән әзерләнгән ризыклар хәләл санала. Шулай ук балыкның бик күп төрләре, бал, бөртекләләр, сөт, сөт ризыклары, иссерткеч булмаган эчемлекләр һәм башкалар да безгә хәләл булды. Ә хәрәм хакында Аллаһы Тәгалә болай ди: "Сез мөэминнәргә үлгән хайван ите, бугаз каны, дуңгыз ите һәм суйганда Аллаһыдан башка затның исеме зикер ителеп суелган хайван ите хәрәм булды, янә буылып үлгән, сугылып үлгән, югары җирдән төшеп үлгән, бер хайван тарафыннан сөзелеп яки тибелеп үлгән хайван ите, янә ерткыч хайван үтергән хайванның ите хәрәмдер, әгәр биртелгән яки ерткыч хайван җәрәхәтләгән хаваннарны үлмәс борын "Бисмилләһи аллаһу әкбәр!" дип әйтеп бугазлап өлгерсәгез - ите хәләлдер. Янә тәреләр яки каберләр өчен бугазланган хайван итләре хәрәмдер. Янә сезгә хәрәм ителде ырымланган уклар белән хөкем итүегез. Ырымның һәртөрлесе дә хәрәмдер" ("Әл-Маидә", 3 нче аять).

Шулай итеп, хәрәм белән хәләл буенча сораулар калмады, чөнки бу хакта Аллаһы Тәгалә Изге Китабында Үзе аңлаткан. Әмма Пәйгамбәребез хәдисләрендә шикле нәрсәләр телгә алына. Андый ризыкны кулланырга ярыймы? Гомумән, нәрсә ул шикле ризык? Менә гади генә бер мисал. Супермаркетта тәмтомнардан сыгылып торган шүрлекләр арасыннан барганда, безнең карашыбыз күз явын алырлык төстәге мармеладларга төшә, ди. Бер карасаң, бу тәмтомның бернинди зарары да юк кебек инде. Әмма бу беренче карашка гына шулай. "Бернинди зарарсыз" шул мармеладны җитештергәндә желатин кулланалар. Желатин, мәгълүм булганча, терлек тиресеннән, сөякләреннән ясала, ә ул терлек хәләл булгандыр, хәләл ысул белән чалынгандыр, дип беребез дә кистереп әйтә алмый. Алай гына да түгел, бүгенге көндә желатинны иң күп җитештерүче ил булып Кытай санала. Ә кытайлар, үзегез беләсез, нинди генә экзотик җанварларны ашамыйлар...

Менә сез, кәрзинегезне күтәреп, яшелчәләр бүлегенә киләсез. Монда инде бернинди шикле нәрсә булырга тиеш түгел кебек. Ләкин андый нәтиҗәләр ясарга ашыкмагыз. Мәгълүм булганча, биоинженерия дигән фән геннарны күчерү ярдәмендә яшелчәләрнең ниндиләрен генә җитештерергә мөмкинлек бирми хәзер. Азык-төлек ярлыкларындагы ГМО (генетически модифицированный организм) дигән язу сез сайлаган ризыкның хәрәм булуы турында сөйли, чөнки шәригать кануннары буенча, кеше сәламәтлегенә зыян сала торган ризык хәләл була алмый. ГМОлы ризыкларның кеше организмына зарары расланса да, кызганычка, җештерүчеләрнең бу эштән туктарга һич исәпләре юк. Шуңа күрә табигый булмаган төстәге яшелчәләрне кәрзинегезгә салмавыгыз хәерлерәк.

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарты комитеты ризык сатып алганда түбәндәгеләргә игътибар итәргә киңәш бирә:**

**1. Ризыкның төргү материалында "хәләл" тамгасы һәм җаваплы оешманың исеме булырга тиеш.**

**2. Хәләл ризыкның составын җентекләп тикшерегез.**

**3. Составында терлек мае, желатин, алкоголь булган продуктларны кулланмагыз.**

**4. Әгәр азык-төлекнең берәр ингредиенты шик уятса, аның турында интернет челтәреннән мәгълүмат эзләгез яки http://halalrt.com/ сайтының "Хәләл турында сорауларыгыз" бүлегенә кереп, "Хәләл" стандарты комитеты вәкилләреннән белешегез.**

**5. Хәрәм яки шикле дип табылган "Е" кодлы ингредиентлар таблицасын үзегездә булдырыгыз.**

**6. Хәләл ит ризыклары хәләл булмаганы белән бергә сакланырга тиеш түгел.**

**7. Терлек кулдан яки механик юл белән чалынганмы - шуңа игътибар итегез. Моның өчен һичьюгы эре җитештерү предприятиеләрендә бу эшнең кайсы ысул белән башкарылуын белү мөһим.**



# СОРАУ - ҖАВАП

***- Балалар бик яратып ашый торган гематоген хәләл микән?***

- Гематоген мөгезле эре терлек канына куертылган сөт, бал, аскорбин кислотасы һәм башка өстәмәләр кушып ясала. Коръәндә: "Сез мөэминнәргә үлгән хайван ите, бугаз каны, дуңгыз ите һәм суйганда Аллаһыдан башка затның исеме зикер ителеп суелган хайван ите хәрәм булды..." - диелә ("Маидә", 3 нче аять). Димәк, гематоген - хәрәм, аны кулланырга ярамый.

# ДӨНЬЯНЫ ЯУЛАСЫЛАР БАР ӘЛЕ

Мөселманнар күпләп яшәгән Көнбатыш илләрендә хәләл азык-төлек базары зур тизлектә үсә. Франциядә, мәсәлән, французларның милли ризыгы саналган бавыр паштетыннан башлап хәләл ризыкларның киң ассортименты тәкъдим ителә. Бөекбританиядә эре супермаркетларда хәләл ит, колбаса ризыклары сатыла. Сатуда балалар өчен хәләл ризыкларга хәтле бар. Кайбер рестораннарда хәләл тавык итенә заказ бирергә мөмкин. Германиядә дә хәләл азык-төлек җитештерүдә шәригать кануннары саклана. Немец җитештерүчеләр ассоциациясе вәкилләре хәләл азык-төлек җитештерүнең бик файдалы бизнес булуын таныйлар.

Дөньяда бүгенге көндә хәләл продукцияне сертификацияләүче 122 оешма бар икән. Аларның һәркайсы, үз милли мәнфәгатьләреннән чыгып, бөтендөнья сертификация үзәге булырак танылырга тели. Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә дөньяның 57 илендә гамәлдә булырлык бердәм стандарт эшләргә кушты. Шундый стандарт кабул ителсә, бу хәләл продукция җитештерү тармагын үстерүгә көчле этәргеч булачак.

*Gulf News*



# БАЛТАЧ ЯРМИНКӘСЕНЕҢ АБРУЕ АРТА

Июль азагында Татарстанның Балтач районында "Балтач-2014" хәләл ярминкәсе узды. Аны "Хәләл" индустриясе милли ассоциациясе, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарты комитеты һәм "Балтач" индустриаль паркы оештырды. Ярминкә ачылышында Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Линар Якупов, Балтач муниципаль районы башлыгы Рамил Нотфуллин, ТҖ МДН нең "Хәләл" стандарты комитеты җитәкчесе Марат Низамов һәм Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев катнашты. Быелгы ярминкәдә "Челны- мясо" җаваплылыгы чикләнгән ширкәте, Alokozay, Bateel, "Бәхетле" сәүдә челтәре актив катнашты. Ярминкәгә Мамадыш, Кукмара һәм башка күрше районнардан да кунаклар килгән иде. Мондый ярминкәләр киләчәктә башка районнарда да оештырылырга мөмкин, кунаклар әнә шундый теләк белдергәннәр.

# АШАГАНЫҢ ХӘЛӘЛМЕ?

Мөселман яшьләр берлеге "Хәләл" стандарты комитеты белән берлектә җәмәгать туклануы урыннарында хәләл ризык әзерләүне тикшерү айлыгын игълан итте. Айлык дәвамында хәләл ризык әзерләүләре хакында белдергән кафелар, рестораннар барлана. Мөселман яшьләре берлеге вәкилләре кафеларда хәләл ризыклар куллану турында мәгълүмат туплый, шулай ук хезмәткәрләр арасында хәләл ризык хакында сораштырулар үткәрә.

"Хәләл" стандарты комитеты җитәкчесе Марат Низамов билгеләп үтүенә караганда, бик күпләр хәләл ризыкның нинди булырга тиешлеге хакында хәбәрдар түгел. "Без чынлап та хәләл ризык ашавыбызга ышанырга тиеш. Әлеге айлык кешеләргә тагын бер мәртәбә хәләл ризык белән тукланырга кирәклекне искә төшерер. Без шәһәрнең барлык хәләл оешмаларында булырга, анда эшләүчеләрне хәләл ризык әзерләү серләренә төшендерергә тырышырбыз", - ди ул.

*Айлык нәтиҗәләре белән "Дин вә мәгыйшәт" газетасының алдагы санында таныштырырбыз.*

# "АЯТЕЛ-КӨРСИ" ТӘФСИРЕ

**Күптән түгел "Хузур" нәшрият йортында *Фәрит хәзрәт СӘЛМӘНнең* "Аятел-Көрси" тәфсире" дип аталган китабы басылып чыкты. Анда Коръәннең иң бөек аяте тәфсир ителә, аны дөрес уку тәртипләре, мәгънәви үзенчәлекләре, серләре, фазыйләтләре җентекләп аңлатыла, әлеге аятьне кайсы вакытта, кайсы урында укыганда нинди саваплар бирүе хакында да әйтелә. Һәркайсыгызга күркәм аятьне укып, аның шифасын, сихәтен тоярга, рухыгызны ныгытырга һәм тормышыгызны бәрәкәтле итәргә язсын, дигән теләк белән әлеге китаптан өзекләр тәкъдим итәбез.**



## ИҢ БӨЕК АЯТЬ

Үбәйй ибне Кәгъб хәбәр иткән: "Пәйгамбәрдән (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) бәрәү: "Йә Рәсүлуллаһ, Аллаһы Тәгалә Китабында кайсы аять иң бөек булыр икән?" - дип сораган. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вәсәлләм: "Аятел-Көрси" ("Көрси" аятедер)... Җаным Аның хөкемендә булучы Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен, ул аятьнең теле дә бар, ике ирене дә бар. Аллаһы Тәгаләнең гареше аягы янында тәсбих әйтеп тора..."- дигән".

## ФАРЫЗ НАМАЗЛАР АЛДЫННАН "АЯТЕЛ-КӨРСИ"НЕ УКУ

Берәү "Аятел-Көрси"не намаз башлар алдыннан укыса, шайтан ул кешенең янына намаз вакытында якын да килмәс. Аллаһы Тәгалә ул кешене дөньядагы бәла-казалардан, һәлакәт-фәлакәтләрдән, шайтанның шәрреннән имин итәр.

## "АЯТЕЛ-КӨРСИ"НЕ НАМАЗДАН СОҢ УКУ

Әнәс хәзрәт радыйаллаһу ганһү тапшырган: "Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм: "Кем, һәр фарыз намазын укып бетергәч, "Аятел-Көрси"не укыса - киләсе намазга кадәр иминлектә булыр. Ләкин пәйгамбәрләр, рас сүзлеләр, шәһитләр генә шулай булдыра алырлар", - дигән.

Хәзрәти Хәсән радыйаллаһу ганһү, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең оныгы: "Кем дә кем "Аятел-Көрси"не фарыз намазлардан соң укып тора икән, киләсе намазга кадәр Аллаһы Тәгаләнең саклавында булыр!" - дигәнне тапшырган.

***

"Тарих Бәгъдад" китабында Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең Ибне Габбас (радыйаллаһу ганһүмә) риваяте буенча хәдис-шәрифе китерелгән: "Кем дә кем фарыз намазын тәмамлаган саен "Аятел-Көрси"не укый икән - Аллаһы Тәгалә аңа шөкрана бәндәләрнең калебен, туры - рас сүз сөйләүчеләрнең гамәлләрен, пәйгамбәрләрнең әҗерләрен бирер. Ул бәндә Аллаһы Тәгалә рәхмәте астында булыр. Аңа җәннәткә китәргә килеп җитмәгән әҗәле генә комачаулап торыр".

***

Әбү Үмәмәһ радыйаллаһу ганһү риваять иткәнчә, Рәсүлуллаһ галәйһиссәләм пәйгамбәребез: "Бер мөэмин биш вакыт намаздан соң "Аятел-Көрси"не укыса, Аллаһы Тәгалә бу мөэминнең җанын нәкъ сугыш кырында шәһит булып киткән пәйгамбәрләрнең җаннарын алган шикелле алыр..."- дип әйткән.

***

"Әй, Гали! Һәр намаз артыннан "Аятел-Көрси" укысаң, шөкер итүчеләрнең калебе, пәйгамбәрләрнең савабы, изге күңеллеләрнең гамәлләре сиңа бирелер", - дигән Пәйгамбәребез Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәсәлләм).

## БӘРӘКӘТ АРТТЫРУЧЫ АЯТЬ

Гайшә ана (радыйаллаһу ганһә) хәбәр иткән: "Берәү Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) янына килеп, өеннән бәрәкәт китүенә зарлана. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәллам бу мескен кешегә: "Син "Аятел-Көрси"не күңелдән белмисеңмени? Син аны тәгам өстенә укыган саен Аллаһы Тәгалә аның бәрәкәтен арттырып торыр!" - дип киңәш-нәсыйхәт биргән".

***

Сахабәләрнең берсе әфәндебез Мөхәммәд галәйһиссәләм хозурына барып: "Йә Рәсүлуллаһ! Өемдә бәрәкәт дигән нәрсә бер дә калмады!" - дигәч, Мөхәммәд галәйһиссәләм: "Син "Аятел-Көрси"не белмисең мәллә? Ул ризык өстендә укылса, Аллаһы Тәгалә аның бәрәкәтен арттырыр. Ул сине дә, гаиләңне, өеңне һәм өең тирәсендәге башка йортларны да саклаячак. Сез аның файдаларын белсәгез, һич ташламас идегез! Яткан вакытта укысаң, җеннәрнең шәрреннән котылырсың вә Аллаһы Тәгалә үзеңә ике фәрештәне вәкил итеп куяр, алар сине саклап торырлар", - дигән.

***

Бәрәкәт арттыру өчен "Аятел-Көрси"не бер кисәк ефәк өстенә 313 мәртәбә укырлар, һәр "Аятел-Көрси" укыган саен укучы кеше шул ефәккә өрергә тиеш булыр. Укып бетерелгәч, бу ефәк кисәге йортның берәр югары урынына эленеп куелыр.

## "АЯТЕЛ-КӨРСИ"НЕ ХӘСРӘТ ВАКЫТЫНДА УКУ

Әбү Катәдәһ тапшырган: "Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам: "Кем дә кем хәсрәт вакытында "Аятел-Көрси" белән "Әл-Бәкара" сүрәсенең ахыргы 3 аятен укыса, Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә ирешер", - дип әйтте".

## ӨЙДӘН ЧЫККАНДА УКЫЛА ТОРГАН "АЯТЕЛ-КӨРСИ"

Мөхәммәд галәйһиссәләм хәзрәти Галигә (Аллаһы Тәгалә аның йөзен нурландырсын!) васыять итеп: "Кем дә кем өеннән "Аятел-Көрси"не укып чыга икән, өенә кайтып җиткәнче Аллаһы Тәгаләнең химаясендә, яклавында булыр. "Аятел-Көрси" укылган йортка утыз көн буена шайтаннар якын килмәс, кырык көн буена сихерче ирләр һәм хатыннар да керә алмас. Ий, Гали! "Аятел-Көрси"не балаларыңа, хатыннарыңа, күршеләреңә өйрәт! Моннан да бөегрәк аять иңмәде әле! Берәү йокыга ятар алдыннан "Аятел-Көрси"не укыса, Аллаһы Тәгалә аның үзен дә, күршесен дә, күршесенең күршесен дә, өе тирәсендә булган өйләрне дә һәртөрле начарлыктан имин итәр. Сүзләрнең әфәндесе - Коръәндер. Коръәннең әфәндесе - "Әл-Бәкара" сүрәсе, "Әл-Бәкара" сүрәсенең әфәндесе исә - "Аятел-Көрси"дер", - дип әйтте.

Шулай ук Пәйгамбәр галәйһиссәләм хәбәр иткәнчә, өеннән чыкканда "Аятел-Көрси"не укучы кешене Аллаһы Тәгалә җитмеш мең фәрештәсенә тапшырыр. Ул фәрештәләр аның өчен истигъфар әйтеп торырлар, ди.

## "АЯТЕЛ-КӨРСИ"НЕҢ СЕРЛӘРЕ

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам "Аятел-Көрси"не көн саен 7 шәр мәртәбә укып, үзенә җен-пәри шәрреннән иминлек сораган.

***

Төн уртасында кыйблага юнәлеп, 170 мәртәбә хәерле ният белән укылган "Аятел-Көрси" хакына теләкләр үтәлер, иншә Аллаһ.

## "АЯТЕЛ-КӨРСИ" ТУРЫНДА ОЛЫ ИШАН-ХӘЗРӘТЛӘР СҮЗЕ

Хәзрәти Баба Фәридуддин Җәнҗ (радыйаллаһу ганһү) болай дигән:

- "Аятел-Көрси" - Коръәннең иң бөек аяте буладыр;
- "Аятел-Көрси"не укучы, җеннәрнең шәрреннән иртән кичкә, кичтән иртәгә кадәр иминлектә булыр;
- "Аятел-Көрси"не уку Коръәннең дүрттән бер өлешен укуга тиң;
- "Аятел-Көрси"не һәр фарыз намаздан соң укучыны җәннәткә керүдән әҗәл җитмәү генә тоткарлап торыр;
- "Аятел-Көрси"не фарыз намаздан соң укучы кеше киләсе фарыз намазга кадәр иминлектә булыр;
- "Аятел-Көрси"не ризык, су өстенә уку ризыкка да, суга да бәрәкәт бирер;
- өйгә кергәндә "Аятел-Көрси"не уку шайтанны өй бусагасы аркылы үткәрмәс;
- "Аятел-Көрси"не укучының үзе дә, гаиләсе дә, малы да, өе дә, күршеләре дә иминлектә булырлар;
- "Аятел-Көрси"не укучы янына карак якын килмәс;
- "Аятел-Көрси" берәр савыт өстенә укылса, ул савытны шайтан ача алмас;
- "Аятел-Көрси"не йокларга яткан кеше укыса, уянганчыга кадәр ул 2 фәрештә карамагында булыр;
- әйберләр өстенә "Аятел-Көрси"не укып өрү аларны шайтаннан саклар;
- өйдән чыгучы кеше "Аятел-Көрси"не укыса, өенә кайтканчы Аллаһы Тәгалә яклавында булыр;
- "Аятел-Көрси" белән "Әл-Мөэмин" сүрәсенең аятьләрен иртән укучы кеше кичкә кадәр, кичен укучы иртәсенә кадәр имин булыр.

***

Котбуддин Бәхтияр (рахмәтуллаһи галәйһи) әйткән:

- Аллаһы Тәгалә өйдән чыкканда "Аятел-Көрси"не укучы кешене мохтаҗлыктан коткарыр;
- авыру кешегә "Аятел-Көрси"не укып өрсәләр, авыруга җиңеллек булыр;
- хастаханәдәге авырулар ята торган бүлмәгә "Аятел-Көрси"не укып өрсәләр, иншә Аллаһ, авыруларга җиңеллек булыр;
- иминлек һәм бәрәкәт өчен "Аятел-Көрси"не 33 яки 99 мәртәбә укырлар;
- куркыныч төшләрдән интегүче кеше йокы алдыннан "Аятел-Көрси"не 3 мәртәбә укысын;
- җомга көннәрдә, икенде намазыннан соң, берьялгызы булган урында "Аятел-Көрси"не 70 мәртәбә укучы кеше нур күрә башлар, бу вакытта догалары кабул булыр.

## "АЯТЕЛ-КӨРСИ" ШИФАСЫ

Явыз хуҗа каршына керер алдыннан "Аятел-Көрси"не уку явызны телсез калдырыр.

## АЧУ ЧЫККАН ВАКЫТТА "АЯТЕЛ-КӨРСИ"НЕ УКУ

Кем дә кем "Аятел-Көрси"не ачуы чыккан вакытта укыса һәм шуннан сул ягыннан төкерсә - янындагы шайтан чигенер һәм ачуы басылыр.

## 313 "АЯТЕЛ-КӨРСИ"

Мәгълүм ки, "Аятел-Көрси"дә 170 хәреф бар, бу аять 50 сүздән тора. Шуңа күрә галимнәр бу аятьне берьюлы 50 яки 170 мәртәбә укырга дип киңәш иткәннәр. Шулай ук "Аятел-Көрси"не берьюлы 313 мәртәбә, ягъни Әсъхәб Талут (Талут юлдашлары, ярдәмчеләре) һәм Бәдер сугышында катнашкан сахабәләр санынча укырга да тәкъдим иткәннәр. Һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәллам исемнәре санынча, ягъни 201 мәртәбә уку да дөрес булыр.


## СЕЗГӘ КИРӘКЛЕ КИТАПЛАР - "ХУЗУР" КИБЕТЛӘРЕНДӘ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты күңелләрне рухи яктан баету һәм ислам кыйммәтләрен тарату максатыннан китаплар нәшер итүне дәвам итә. Нәшрият йорты кибете киштәләреннән киң катлам укучыларга тәгаенләнгән китапларны да, имамнарга, башлангыч дини белем бирүчеләргә аталган басмаларны да табып була.**

**"ХУЗУР" нәшрият йортының сайты - huzur.ru.**

**Казандагы кибетләре адреслары: Лобачевский урамы, 6 нчы йорт һәм Газовая урамы, 19 нчы йорт.**

***Заказ бирү өчен телефоннар: (8843) 2-02-07-74; 8 (965) 596 5537.***



# Ана капиталы хәләл микән?

## Сораугa Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН җавап бирә

***- Элек ана капиталы өчен 250 мең сум бирәләр иде, хәзер - 430 мең сум. Бу риба булып исәпләнмиме?***




- Хәнәфи мәзһәбенең абруйлы "Әл-Лүбәәбү фи шәрхи әл-Китәәб"ендә болай дип әйтелгән: "Риба" сүзе гарәп телендә теләсә нинди өстәмәне аңлата, шәригать терминологиясендә исә риба - шәригать үлчәмнәре (күләм, авырлык һ.б.) белән үлчәнә ала торган һәм тиешле алмашынуы булмаган артыклык. Ә бу үлчәм берәмлеге мөлкәт алмашуда катнашучыларның берсе тарафыннан шарт итеп куелган булырга тиеш".

Бу хакта Имам ән-Нәсафинең "Канзү-Дәкаикъ" китабында да "товарны товарга алмашкан вакытта алмашынуы булмаган артыклык" дип әйтелгән.

Моңа дәлил итеп хәдис китерик. Әбү Сәгыйд әл-Худридан Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) шушы сүзләрен тапшырлар: "Алтын - алтынга, көмеш - көмешкә, бодай - бодайга, арпа - арпага, хөрмә - хөрмәгә, тоз - тозга һәм бердәй кыйммәтлелектә - кулдан кулга. Ә кем өстәгән яки өстәүне сораган - риба кылган булып исәпләнә, һәм дә бу вакытта бирүче кешенең гөнаһы алучы кешенең гөнаһына тигез" (Мөслимдә китерелгән).

Алда әйтелгәннәрдән чыгып, бу очракта "риба" (ростовщиклык) юк, ә бу акчалар сезгә дәүләтебездән бүләк һәм ярдәм, һәм бу игелекле эш булып тора. Моның игелекле эш булуы Кәламе шәриф сүзләре белән дәлилләнә: "Ий мөэминнәр! Яхшы эшләрдә, изге гамәлләрдә гөнаһлардан, золым эшләреннән сакланууда ярдәмләшегез! Әмма гөнаһлы эшләрдә һәм дошманлашуда яки золым эшләрендә һич тә ярдәмләшмәгез! Аллаһтан куркыгыз, аның вәгазьләрен, хөкемнәрен игътибарсыз калдырудан сакланыгыз! Дөреслектә Аллаһ сакланмаучылардан каты газап белән үч алучыдыр" ("Маидә (Аш яулыгы)" сүрәсе, 2 нче аять).

Мөслим җыентыгында Әбү Һурайрадан (Аллаһ аңардан разый булса иде!) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның салаваты вә сәламе ирешсә иде!) шул сүзләре тапшырыла: "Кем бу дөньяда мохтаҗның хәлен җиңеләйтә, Аллаһ ахирәттә аның хәлен җиңеләйтер, кем мөселманга шәфәгать күрсәтә, Аллаһ ул кешегә бу дөньяда һәм ахирәттә шәфәгать күрсәтер; Аллаһ үз колына ул башка мөэмин туганнарына ярдәм иткән вакытта ярдәм итә".

# НИНДИ ХАТЫН-КЫЗ БЕЛӘН НИКАХЛАШУ ТЫЕЛА

***Мөселман кешегә кайбер хатын-кызлар белән никахлашу тыела. Нинди хатыннар соң алар?***

1. Шәригать кануннары буенча ир кеше өч тапкыр талак әйткәннән соң хатыны белән кабат никахлаша алмый. Никахлашырга теләгән очракта бу хатын башка ир-атка кияүгә чыгып, аның белән якынлык кылырга тиеш. Яңа ире үлеп китсә, яисә аерылышкан очракта гына, хатынның беренче ире аның белән яңадән никахлашу хокукына ия була.

2. Дүрт хатыны булган ир-атка бишенче хатын белән никахлашу тыела.

3. Бер үк вакытта бертуган хатын-кызлар белән никахлашу тыела.

Мөселман ир-аты шулай ук хатынының әтисе яисә әнисенең кыз туганы; хатынының оныгына да өйләнә алмый. Бу хатын-кызларның канкардәшләр яисә сөт туганы булуы мөһим түгел. Мондый никахлар хатыны үлеп киткән яки аерылышкан очракта гына укыла ала.

4. Исламда башка кеше хатыны белән никахлашу хәрәм санала. Хатын-кыз бары тик бер генә ирнең хатыны була ала.

5. Ире белән аерылышканнан соң яисә ире үлгәннән соң билгеле бер вакыт үтмичә торып (идда), ул хатын-кыз белән никахлашу тыела.

6. Мөселман кешегә Аллаһы Тәгаләнең Китапларына иярмәгән хатыннарга - потларга яки утка табынучыларга, дәһри яисә сектантларга өйләнү тыела. Хатын-кыз исламны кабул иткән очракта алар никахлаша ала.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фикере буенча, мөселман кешегә иудаизм яки христиан динендәге хатын-кыз белән никахлашырга мөмкин, әмма бу хупланган никах түгел (шәфигый мәзһәбе буена мондый никах бөтенләй рөхсәт ителми). Шул ук вакытта иудаизм һәм христиан динендәге ир-ат белән мөслимәнең никахлашуы тыелган гамәл, зина булып санала.

# Авыр булса, ташлап калдыр



Бервакыт бер шәкерт үзенең остазына болай дип мөрәҗәгать итә икән:

- Син шундый зирәк, кәефең дә һәрвакыт яхшы, беркайчан ачулы чагыңны күргәнем юк. Мине дә шундый булырга өйрәт әле.

Остазы шәкертеннән бәрәңге һәм үтәкүренмәле капчык алып килүен сораган.

- Әгәр дә син кемгә дә булса үпкәләсәң, бәрәңгенең бер ягына үз исемеңне, ә икенче ягына үпкәләткән кешенең исемен яз. Аннары аны шушы капчыкка салып куй.

- Шул гынамы? - дип аптырап сораган шәкерт.

- Юк, - дигән остазы, - син бу капчыкны һәрвакыт үзең белән йөрт. Һәм берәрсенә үпкәләгән саен имзаланган бәрәңгене сала бар.

Шәкерт шулай эшли башлый. Берникадәр вакыт үтә, шәкертнең капчыгы да шактый авырая. Җитмәсә, баштарак салынган бәрәңгеләр бозылып, начар ис чыгара. Шәкерт түзми, остазы янына барып:

- Мин бу капчыкны башка күтәреп йөри алмыйм. Беренчедән, ул бик авыр, икенчедән, бәрәңге бозыла. Син миңа башка нәрсә тәкъдим ит инде,- дигән.

Шул чакта остазы аңа болай дип җавап биргән:

- Менә синең җаның да нәкъ шундый хәлдә. Кемгә дә булса үпкәләгәндә, күңелеңне авыр таш баса башлый. Син аны башта сизмисең әле, аннары ташлар күбәя, авырая... Шундый авыр йөкне күтәреп йөрү нигә кирәк сиңа? Ә бит ул йөктән котылу өчен "капчыкка бәрәңге тутырып йөрмәскә" кирәк - бары шул гына,- дигән.

***Islam-Today***

# ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

***Фәрештәләр исемен кушарга ярыймы? Аллаһы Тәгалә Коръәннең "Зүгъруф" сүрәсендә болай ди: "Аллаһның хезмәтендәге фәрештәләрне дә алар хатын-кызга саныйлар. Әйтерсең ки, алар фәрештәләрнең яралтылышын күреп торган. Гаҗәп. Аларның бу ялган шаһитлыгы язылып куелачак һәм алар җавапка тартылачак" (19 нчы аять).***

Бу аятьтән мөшрикләрнең фәрештәләрне хатын-кыз җенесенә кертүләрен аңлыйбыз. Аллаһы Тәгалә аларның болай кылануларын яратмый һәм аларны шелтәләп кенә калмый, бәлкем "җавапка тартылачаклар" дип куркытып та куя. Инде без мөселманнар үзебезнең хатын-кызларыбызга фәрештәләрнең (Җәбраил, Микаил, Исрафил) дигән исемнәрне дә кушсак, ул чагында мөшрикләр: "Әнә мөселманнар да үз хатын-кызларына фәрештәләрнең исемнәрен кушалар, бу бит фәрештәләрнең хатын-кыз җенесеннән булуын аңлата", - дип әйтүләре бар. Шуңа күрә ислам галимнәре мөшрикләргә сәбәп булмасын өчен хатын-кызларга андый исемнәрне кушудан тыйганнар һәм дөрес тә эшләгәннәр. Ә ирләргә килгәндә, киресенчә, "ярамый" дигән кисәтүче, тыючы дәлилләр юк. Шулай булгач, андый исемнәрне кушу хәрәм дә, мәкруһ та түгел, иншә Аллаһ. Кыскача әйткәндә, мөшрикләргә берничек тә охшарга, аларның кагыйдәләренә туры китереп гамәл кылырга ярамый.



**ИР-АТ ИСЕМНӘРЕ**

Аршат (гарәп яки фарсы) - иң акыллы, өлкән, югары дигән мәгънәне белдерә
Асаф (г.) - яхшы сыйфатлы, уйчан, хәстәрле
Аслан (төрки-угызча) - Арыслан
Асман (ф.) - күк йөзе
Асылбай (г.-төр.-татар) - асыл бай, күркәм ир бала
Асылбәк (г.-төр.-т.) - асыл бәк
Асылгәрәй (г.-төр.-т.) - Асыл + Гәрәй
Асылзат (г.) - күркәм зат
Атабай (төр.-т.) - өлкән бай
Атнабай (ф.-төр.-т.) - җомга көн туган ир бала

**ХАТЫН-КЫЗ ИСЕМНӘРЕ**

Бакирә (г.) - гыйффәтле кыз
Балкыш (болгар-татар) - балкып торучы
Бану (ф.) - бикә, кәләш
Бария (г.) - бар итүче
Баянсылу (монгол-төр.-т.) - бәхетле сылу
Биби (ф.) - кыз бала, бикә, ханым
Бибигөл (ф.) - Биби + гөл
Бибикамал (ф.-г.) - Биби + Камал (өлгергән, камил)
Бибиназ (ф.) - Биби + наз
Бибинур (ф.-г.) - Биби+ Нур

***Гомәр Саттарның "Исемең матур, кемнәр куйган?" китабыннан***

# БАЛАЛАРЫ БУЛМАСЫН ӨЧЕН ЯСАЛГАН БОЗЫМНАН ДӘВАЛАУ

*Бу бозымны ирләргә дә, хатыннарга да ясыйлар. Бозымга җаваплы җен ирнең җенес әгъзаларына тәэсир итә, нәтиҗәдә сперматозоидларның күләме тиешле дәрәҗәгә җитми. Моннан тыш җен сперматозоидның яшәвен тәэмин итә торган тимергә җимергеч йогынты ясый.*

*Хатын-кызларда җен аналык бизләрен зарарлый. Нәтиҗәдә хатын балага уза алмый. Кайвакытта балага узу уңышлы да булырга мөмкин. Ләкин бу вакытта җен аналыктагы кан тамырларына зыян салып, бала төшә.*

*Бу төр бозымга күкрәк кысу, зиһен чуалу, бил авырту, тынычсыз йокы, яман төшләр күрү һ.б. хас.*

*Түбәндәге чараларны кулланып дәвалау тәкъдим ителә:*

*- иртәләрен "Саффат" сүрәсен укырга яки тыңларга;*

*- йоклар алдыннан "Мәгариҗ"сүрәсен укырга яки тыңларга;*

*- тмин маена Коръәннең 1; 2:255, 285-286; 3:200 аятьләрен һәм җиде мәртәбә 112, 113, 114 нче сүрәләрен укып, шуның белән йоклар алдыннан авыруның күкрәген, маңгаен һәм умыртка баганасын майларга;*

*- шул ук аятьләрне корт балына укып, һәр көнне ашар алдыннан бер кашык кабарга.*

*Дәвалауны 3 ай дәвам итәргә.*

***Хасса бинт Рашид бине Габдуллаһ әл-Мәзәнинең "Коръән белән шифа табу" китабыннан***

Хатларыгызны Диния нәзарәтенә(Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз

# "ҮЗЕМӘ КИРӘКНЕ МИН МОНДА ДА ТАПТЫМ"

Байтактан бирле аралашып, хәл-әхвәл белешеп йөрешсәк тә, Илбик абый никтер үзе турында ачылып китеп сөйләргә ашыкмады, карап торышка кырысрак кеше ул. Язмышы да гади генә түгел, ахры, Казанга Үзбәкстаннан кайтып төпләнгән, үз гомерендә берничә мәчетне төзүдә башлап йөргән, диләр. Беркөнне, ниһаять, безне эш бүлмәсенә дәшеп керттe дә, үзе сөйләсе урынга ноутбугын кабызып куйды. Һәм без, дөньябызны онытып, аның турында мавыктыргыч фильм карадык...

Йөзем куаклары, алмагач, шәфталулар үсеп утырган бик зур ишегалдындагы табыннар артына үзбәк түбәтәе кигән картлар, ир-егетләр тезелешкән. Ишегалды уртасында басып торган урта яшьләрдәге ир янына (Илбик абыйның унбиш яшькә яшьрәк чагы) килеп, аңа хәерле сәфәрләр телиләр, аннан кочакларына кысып, дусларча шап-шоп иттереп аркасыннан кагалар. Дин әһелләре, генераллар, зур-зур түрәләр... Илбик абый сул кулын йөрәк турында тоткан көе тыенкы гына сөйләшә, рәхмәтләр әйтә, вакыт-вакыт күзләре дымланып китә. Бу - озату кичәсе икән. Дуслары, якыннары, райондашлары аны шулай зурлап Татарстанга озата.

Илбик абый Шәйдуллин Үзбәкстанның Сәмәрканд өлкәсендә, Пайарык районында туып үскән. Пайарыкны хәзер Әл-Бохари дип йөртәләр. Шушы районндагы Хартанг дигән кышлакта бөек ислам дине тәгълиматчысы Бохари җирләнгән, бу ислам дөньясындагы иң изге урыннарның берсе санала. Пайарыкка Илбик абыйның әтисен - белемле прокурорны 1934 нче елда эшкә җибәргән булалар, Татарстанның Теләче районы Зур Мәтәскә авылы кызы белән алар шушы җирдә төпләнеп яшәп калалар, өч кыз, 2 малай тәрбияләп үстерәләр. Бик хөрмәтле гаилә була бу. Район үзәгендә 300 ләп татар яши, Илбик абыйның әтисен алар үзләренең аксакалы итеп сайлап куялар, үлем-китем буламы, бала туамы, гаиләдә низаг килеп чыгамы - бар да тизрәк аксакалга йөгереп килә. Әтисе үлеп киткәндә Илбик абый әле бик яшь була, әмма халык аның әтисе урынында калуын тели. Менә шулай итеп, аңа - 25 яшьлек егеткә аксакал булырга, милләттәшләрен кайгыртырга туры килә. Һәм, әлбәттә инде, шундый абруйлы кешегә намаз укымый йөрү килешми, ул намазга баса.

Аның хезмәт кенәгәсендә ике генә эш урыны күрсәтелгән: 10 ел ДОСААФта балалар белән эшләгән һәм автобазада 30 ел буе машина йөрткән. Беренче мәчетен дә шул үзе эшләгән ДОСААФ территориясендә төзеткән ул.

- Дөресрәге, ДОСААФка бер катышы да юк иде ул җирнең, караучысыз ташландык бер урын, - дип төзәтмә кертә Илбик абый. - Шулай да бирәселәре килми. Тарткалаша-тарткалаша, артыннан йөри-йөри рөхсәт алып, 300 кешелек мәчет төзеп куйдык. Шуны күреп йөргән бер сәүдәгәр, акчам бар, тагын бер мәчет төзет әле, син булдырасың аны, дип килгән. Киттем мин райкомның беренче секретарена җир сорап. Төрмәгә утырту белән янап, куып чыгардылар үземне. Анда бер иске зират урыны бар иде, совет чорында шуның яртысында кирпеч заводы эшләп торды, аннары аны таркатып бетерделәр, урыны чүплеккә әйләнде. Без менә шул урынга ризалаштык. Аллага тапшырып, бер куй чалып канын чыгардык та, дустымның бульдозерына утырып теге урынны тигезләп куйдым. И-и ул мәчет төзелеше аннары майлагандай барды инде! Сәмәрканд мөфтие Усманхан хәзрәт (ул соңыннан бөтен Үзбәкстан мөфтие булды) үзенең фатихасын бирде. Кирпеч заводына кирпеч сорап барган идем, анысы хаҗи икән, кирпечне ярты хакка төяп җибәрде. 15 кешелек бригаданы мәхәллә халкы 7 ай буена чиратлашып ашатты. Беркөнне төзелешкә килсәм, райкомның беренче секретаре чыгып бара машинасына утырып. "Мөселманның һәркайсы мондый эшкә алынмас! Әйт, нинди ярдәм кирәк?" - ди. Кирпеч җитеп бетми иде, 5 мең кирпеч сорадым.



Төзелеп бетсә дә, Үзбәкстандагы вазгыять белән бәйле рәвештә, мәчет шактый вакытлар ачылмый тора, Президент Кәримовның мәчетләрне ачтырырга рөхсәте юк, 300 мәчет шул хәлдә, диләр. Рөхсәт алу өчен тагын мөфтинең ишеген шакырга туры килә. Ярдәм итә мөфти, тәвәккәлләп рөхсәт кәгазе тоттырып чыгара. Татарстанга күчеп китәргә нияте барлыгын әйткәч тә аны аңлаучы, фатихасын бирүче шул мөфти хәзрәт була. "Син безнең өчен барысын да эшләдең, инде бар, ата-бабаң җиренә кайтып төплән", - ди ул аңа.

Шунда туып үсмәсәң дә, ата-баба туфрагы барыбер тарта, ахры! Башта ике апасы Казанга кайтып төпләнә, аннары абыйсы. Тик абыйсына биргә кайтып озак яшәргә язмаган икән, 2000 нче елда ул вафат була. Менә шул елны абыйсының кырыгын укытырга кайткач, Илбик абый Мәдинә мәчетендә Хатый абый Бикмөхәммәтов белән таныша. Икенче тапкыр алар биш ел үткәч, очраклы төстә троллейбуста очрашалар. Ул чакта инде Илбик абый Казанга бөтенләй күченеп кайткан була. "Мәчет төзедем дигән идең, әйдә, кил, миңа синең ярдәмең кирәк", - ди аңа Хатип абый. Менә шуннан соң бергәләп алар Казанның Гаилә мәчетен төзү эшенә керешәләр. Ә бүгенге көндә шул мәчеттә имам вазифасын башкаралар.

Экранда күргән сюжетлар һаман минем күз алдымнан китми. Хан сарaедай йортын, туып үскән җирен, дусларын шулай җиңел генә ташлап кайтып китүен һич башыма сыйдыра алмыйча, төпченүемне дәвам итәм:

- Үзбәкстан - Сезнең туган җирегез. Анда да бик хөрмәт иткәннәр үзегезне, җибәрәселәре дә килмәгән. Бай мул тормышта яшәгәнсез. Нәрсә тартып кайтарды Сезне монда?

- Алтмыш яшемне тутыруга атам-анам йортына кайтырга дигән ниятем бар иде минем. Туганнарым да, кайт та кайт, диюдән һич туктамады. Советлар Союзы таркалгач, чит илдә каласылары килмәде, ахры, татарларның барысы да диярлек Россиягә кайтып китте. Үзем әйберләрен төяшеп, озатышып йөрдем. Үзбәкстанда беркемем дә калмады: олы кызым Венера белән кечесе Илмара әниләре янында Бакчасарайда, уртанчы кызым Ленара гаиләсе белән Америкада яши. Адәм баласын ризыгы йөртә бит, кайтам дип кенә мин дә кайта алмаган булыр... Ә монда кайтканыма бер генә мизгелгә дә үкенгәнем булмады. Үземә кирәк булган нәрсәне - мәчетне һәм кешеләрнең хөрмәтен мин монда да таптым...

**Мәрьямбану ХАФИЗ**

## РӘХМӘТЕМНЕ ӘЙТӘ АЛМАДЫМ...

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Тормыш юлымдагы бер хата турында сөйлисем килә, барчагызга да гыйбрәт булсын әле.

Яшь чагымда мин бик яхшы бер апаны очраттым. Ул мине туй мәҗлесендә күреп, үзенә туган тиешле бер егет белән таныштырды. Аннары безнең никахыбызда ире белән хөрмәтле кунаклар булдылар.

Аллага шөкер, җәмәгатем белән 16 ел бергә яшибез, инде балаларыбыз да зур егетләр булып үсеп киләләр. Ләкин әллә яшьлек җилбәзәклеге, әллә надан булганбыз, шул ханымны иптәше белән парлап кунакка чакырып, тәм-томнар белән чәй эчертеп, бүләкләр биреп, зур рәхмәтләр әйтә белмәдек. Хәзер инде еш кына уйлыйбыз - әгәр шул вакытта ул хатын безне таныштырмаган булса, язмышларыбыз ничек булыр, кайсыбыз кем белән никахлашыр иде, улларыбыз нинди нәселдән туган булыр иде икән? Балаларыбызга да әйбәт мөселман кызлары белән никахлашып, бәхетле гомер кичерергә насыйп булса иде.

Соң булса да, зурлап кунакка дәшәр, бүләкләр дә бирер идек тә, ләкин ул ханым да, аның ире дә мәрхүмнәр инде. Урыннары җәннәттә булсын, догадан калдырмаска тырышабыз үзләрен.

Бу тормыш юлында безнең эшлисе бик күп эшләребез, үтәсе бик күп юлларыбыз, хәл итәсе бик күп проблемаларыбыз бар. Һәм менә шул проблемаларны чишәргә кемдер сүзе белән, кемдер гамәле белән, кемдер хәтта акча белән дә ярдәм итә. Шул ярдәм өчен вакытында рәхмәт әйтә белергә кирәк. Юкса бүген үк әйтмәсәк, иртәгә соң булуы бар, гомерләр бик кыска бит.

**Гөлфия ТАҖИЕВА,**
**Казан**

## АЛЛАҺЫГА ШӨКЕР КЫЛАМ

Аллаһыга шөкер кылам исәнлек биргәненә,
Аякларым йөргәненә, күзләрем күргәненә;

Аллаһыга шөкер кылам нигъмәтләндергәненә,
Аятьләрне ятлар өчен зиһеннәр биргәненә;

Аллаһыга шөкер кылам якты көн биргәненә,
Күктән яңгырлар яудырып, иген үстергәненә;

Аллаһыга шөкер кылам караңгы төннәренә,
Намазларны укыр өчен ярдәмен биргәненә;

Аллаһыга шөкер кылам ураза биргәненә,
Бәндәләрнең гөнаһларын ярлыкыйм, дигәненә;

Аллаһыга шөкер кылам ак карлы кышларына,
Җәйге матур ал таңнарда сайраган кошларына;

Аллаһыга шөкер кылам сабырлык биргәненә,
Сабырлыкның савапларын бирермен, дигәненә;

Аллаһыга шөкер кылам иманга кайтканыма,
Намаз укып, Коръән укып тынычлык тапканыма.

**Рәшидә ГАЛИЕВА,**
**Казан**

# ҖИРДӘГЕ АЛЛАҺ ЙОРТЛАРЫ

**Җир шарында мәчетләр - Аллаһ йортлары булмаган урыннар инде, шаять, калмагандыр. Аларның тарихлары, зурлыклары төрле, кайсылары карап торышка гади генә, ә кайберләре хан сарайларын хәтерләтә. Бу сәхифәдә ислам архитектурасының "энҗе бөртекләре" булып саналучы мәчетләрнең кайберләре белән танышырбыз.**

Согуд Гарәбстанында, Мәккә шәһәрендәге ***ӘЛ-ХӘРАМ*** мәчете зурлыгы ягыннан беренче урында тора, анда берьюлы 4 миллион мөселман гыйбадәт кыла ала, гомуми мәйданы 88,2 га ны тәшкил итә. Аның тарихы 638 нче елдан башлана. Мәчетнең 89 метр биеклектәге 9 манарасы бар, эчке ишегалдында Кәгъбә урнашкан. Әл-Хәрам мәчете торган шушы урында Адәм галәйһиссәлам Җирдәге беренче гыйбадәт йортын төзегән диләр. Гыйбадәтханә Бөтендөнья су басуы вакытында җимерелгәннән соң, Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам аны шул нигездә кабат торгызганнар.



Төркиянең Стамбул шәһәрендәге ***АЙЯ-СОФЬЯ*** мәчете - элек православие гыйбадәтханәсе булган. Византия империясе чорында Константинопольнең үзәгендәге бу бина император сарае белән янәшә урнашкан булган. Шәһәр Госманлы империясе кулына күчкәннән соң, Софья соборы мәчеткә әйләндерелеп, аның түбәсендә дүрт манара калкып чыга, ә 1935 нче елдан ул музей статусын йөртә. 1985 нче елда исә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас объекты исемлегенә кертелде.



Согуд Гарәбстанында, Мәдинә шәһәрендәге ***КЫЙБЛӘТӘЙН*** мәчете - дөньядагы ике михраблы бердәнбер мәчет, аларның берсе - Иерусалимга, икенчесе Мәккәгә карап тора. Кыйблатәйн мәчете Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәлам Мәдинәгә күчеп килгәннең икенче елында пальма агачы һәм яфракларыннан гына төзеп куелган була. Мөселманнар 16-17 ай дәвамында йөзләрен Әл-Әкъса мәчетенә каратып намаз укыганнар, шуның аркасында яһүдиләр үзләрен өстенрәк дип күрсәтергә тырышканнар. Бу хәл Пәйгамбәребез галәйһиссәламне борчуга салган, ул Аллаһы Раббыбыздан кыйбланы үзгәртү турында вәхи көткән. Ниһаять, ул көн килеп җиткән - шәгъбан аеның 15 нче көнендә Пәйгамбәребез (с.г.в.) намазның икенче ракәгатен тәмамлагач, йөзен Кәгъбә тарафына борган.



Мәдинә шәһәрендәге ***ӘЛ-КУБӘ*** мәчете - ислам тарихындагы беренче мәчет санала. Аның нигез ташларын Пәйгамбәребез (с.г.в.) үз куллары белән салган, бина исә аның замандашлары тарафыннан төзелеп беткән. Соңыннан берничә тапкыр реставрацияләнгән. Бүгенге көндә ул иң гүзәл һәм мәһабәт мәчетләрнең берсе.



Касабланкадагы ***ХӘСӘН II МӘЧЕТЕ*** Атлантик океан ярына урнашкан. Аның пыяла залы берьюлы 25 мең мөселманны сыйдыра, тагын 80 мең кеше мәчет янындагы мәйданда гыйбадәт кыла ала. Бу бинаны Марокко короле Хәсән II 1980 нче елда төзеткән. Аның пыяла идәне аша океан дулкыннары тәгәрәшкәнен күзәтергә мөмкин, ә дулкыннар 10 ар метрга күтәрелгәндә, мәчет яртылаш су астында калып, йөзеп баручы корабны хәтерләтә. Архитектура үзенчәлеге ягыннан аңа тиңнәр булмаса да, зурлыгы буенча ул дөньяда икенче генә урында.





***ДӘҺЛИНЕҢ ҖАМИГЪ*** мәчете - зурлыгы буенча сигезенче урында тора. Ул иң борынгы һәм матур мәчетләрнең берсе, 1656 нчы елда төзелеп беткән. 40 ар метр биеклектәге ике манаралы бу мәчеттә берьюлы 25 мең мөселман гыйбадәт кыла ала. Көньяк манараның иң югары очына бик тар баскычтан күтәрелсәң, Иске шәһәрнең гүзәл манзарасы уч төбендәге кебек күренә. Һиндстанның мәдәни һәм дини кыйммәте саналучы бу бинада Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең аяк киеме, чәч һәм сакал бөртекләре, Коръәннең Мөхәммәд пәйгамбәр үзе әйтеп яздырган бүлеге, Коръәннең болан тиресенә язылган күчермәсе саклана.

Стамбулның (Төркия) ***ЗӘҢГӘР МӘЧЕТЕ*** 19 яшьлек солтан Әхмәд I әмере буенча 1609-1616 нчы елларда төзелә. Алты манаралы бу мәчетнең гөмбәзләренә Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләре, Изге Коръән аятьләре язылган. Мәрмәр диңгез ярында - Айя-Софья музее каршында урнашкан бу гүзәл бинаның эчке диварларын ак һәм зәңгәр төсләрдәге керамика белән бизәгәннәр, исеме дә шуннан килеп чыккан. Мәчетнең 260 тәрәзәсе бар, шуңа күрә анда бик якты. Мәрмәрдән ясалган михрабына Мәккәдән кайтартылган кара таш урнаштырылган. Мәчет янәшәсендәге төрбәдә Солтан Әхмәд I җирләнгән.



***МАЛИНЫҢ ДЖЕННЕ ҖАМИГЪ*** мәчете 1909 нчы елда кызылбалчыктан төзелгән. Ул XIII-XIV гасырлардагы элеккеге җамигъ мәчет урынында өч метр биеклектәге платформага урнаштырылган. Бина үзе 75 метр биеклектә, ә манаралары 50 метрга күтәрелә. Ул күптән түгел генә электрлаштырылган. Мәчет эченә Малидагы кагыйдәләр буенча бары тик мөселманнар гына үтә ала. Дженне җамигъ мәчете 1988 нче елда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас объекты исемлегенә кертелгән.



# "МОНДЫЙ БӘЙРӘМНӘР БИК КИРӘК"

## КАЗАНДА ТӨРЕК НӘШИД БАШКАРУЧЫЛАРЫ ЧЫГЫШ ЯСАДЫ

**Казанда Ураза гаетенә багышлап зур хәйрия концерты узды. Бу - танылган чит ил музыкантлары катнашында оештырылган икенче шундый бәйрәм. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте үткән ел Европаның мәшһүр автор-башкаручысы Сәми Йосыф чыгышын оештырган иде. Быел Төркиядән Седат Учан белән Месут Куртис килде. Шулай ук үзебезнең татар музыкантлары да ислам динен олылаучы җырларын башкарды.**





Ураза бәйрәме уңаеннан концертны бу юлы башкаладагы иң зур корылма - "Казан Арена" янындагы мәйданда үткәрделәр, стадионның олы телеэкраннарыннан сәхнә уч төбендә кебек күренеп торды.

- Ураза гаетенә багышлап икенче тапкыр концерт оештырабыз, алга таба бу бездә традициягә кереп китәр дип уйлыйбыз, - дип фикерләрен җиткерде Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин. - Концертта катнашырга дөньяда бик күп тамашачыларның күңелен яулаган талантлы нәшид башкаручыларны эзләдек. Мөселман җырларын башкаручы Мәһир Зейн белән дә элемтәгә чыккан идек, әмма аның Дубайда чыгыш ясыйсы бар иде. Шуңа күрә төрек музыкантлары Месут Куртис белән Седат Учанны чакырырга булдык. Месут Куртис ул Мәһир Зейн һәм Сәми Йосыф белән дә иҗади хезмәттәшлектә яши. Алар бик мәгънәле һәм моңлы җырлар башкара. Казанга тәкъдим ителүче программаны да бергәләп сайладык. Месут Куртистан, мәсәлән, төрекчә генә түгел, гарәп һәм инглиз телләрендәге җырларын да яңгыратуын сорадык.

Бәйрәм сәхнәсеннән тамашачыларны Ураза гаете белән тәбрикләп, мөфти иң изге теләкләрен җиткерде. Кешеләрне мәрхәмәтле булырга өндәде.

- Башкаларга мәрхәмәтле булган бәндәгә, Раббыбыз да мәрхәмәтле булыр, дигән Пәйгамбәребез (с.г.в.). Аллага шөкер, Рамазан айларын күркәм итеп уздырдык, мәрхәмәтле гамәлләр кылдык, изге эшләргә өндәдек. Рамазан аенда башлаган игелекле гамәлләрне изге ай тәмамлангач та дәвам итсәк иде. Аллаһы Тәгалә халкыбызга, динебезгә, илебезгә яңа көч-куәт бирсен, тоткан уразаларның, биргән фитыр сәдакаларыбызның әҗер-савапларын күрергә насыйп булсын! - дип теләде Камил хәзрәт Сәмигуллин.




Бәйрәм кичендә Татарстан Диния нәзарәте янә бер хәйрия акциясе дә үткәреп алды. Украинадан Татарстанга аяк баскан качакларга матди ярдәм күрсәтү йөзеннән халыктан хәер акчалары җыелды. Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм Батров: "Украина җирендәге канкоештан качып, йортмилкен ташлап, меңләгән халык читкә чыгып китәргә мәҗбүр булды. Татарстан да йөздән артык качакны кабул итте. Аларга бергәләп ярдәм итик", - дип мөрәҗәгать итте. Хәер акчаларын 7715 номерына "Зәкят" сүзе язылган СМС аша җибәрергә яки мәйдандагы махсус тартмаларга салырга мөмкин иде. "Бу кичтә җыелган акчалар Диния нәзарәтенең "Зәкят" фонды аша Украина качакларына булышуга тотылачак", - диде мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт.

Концерт программасын исә Татарстанның атказанган артисты Фәнис Җиһаншин алып барды. Татарстанда мөнәҗәтләр, дини җырлар башкару осталары Фәрит Хәләветдинов, Ильяс Халиков, "Риваять" ансамбле, Руслан Габитов, Илгиз Шәйхразиев чыгыш ясады. 8 сыйныфта гына укыса да, моңлы җырлар яратучы Ильяс Минһаҗевны казанлылар беренче тапкыр тыңлады. Алардан соң төрек кунакларына чират җитте.

Седат Учан Татарстан халкына атап бик күп җылы сүзләр әйтте. 39 яшьлек төрек җырчысының дини белеме дә бар. Ул актив карашлы шәхес, үз илендә һәрдаим телевизион тапшыруларда, җәмәгать очрашуларында да катнаша. Ислам динен данлаучы нәшидләрне яратып башкара. Ел саен диярлек музыкаль җыентык яздыра икән, аларның саны инде 12гә җыелган.

- Мин Аллаһыбызны мактаучы, динебезнең гүзәллеген күрсәтүче, мөселманнарны берләштерүче җырлар башкарырга тырышам. Аларны Татарстан халкына да ирештерә алуыма шатмын, - дип Казанга сәяхәтеннән алган хис-тәэсирләре белән уртаклашты Седат Учан. - Татарстанга мин тәүге тапкыр килдем. Кол Шәриф мәчетендә җомга намазы укырга, Казан Кремленең истәлекле урыннары белән танышырга өлгердек. Татарстанлыларга, Диния нәзарәтенә безне шулай җылы каршы алулары өчен рәхмәтебезне җиткерәм. Үзебезне туганнарыбыз арасында кебек хис иттек. Без бит барыбыз да бер Аллаһтан яралтылган, дөньяда тынычлык урнашсын, күңелләрдә иман, җаннарда ышаныч булсын, - дип теләде ул.



Концерт барышында Седат Учан татар җырчылары белән дуэт та тәкъдим итте. Ильяс Халиков төрек башкаручысының иҗатын бик тә хөрмәт итә икән, аның "Тәүбә кыл" әсәрен татарчага тәрҗемә иткән. Аны Седат бей белән алар төрек һәм татар телләрендә бергәләп яңгырattы.

Кичке күктә яңа ай балкыганда концерт программасы Месут Куртис чыгышы белән тәмамланды. Ул казанлыларга әле күптән түгел генә дөнья күргән яңа альбомындагы әсәрләрен бүләк итте. Төрек җырчысы тумышы белән Македониядән. Шулай ук ул Англиядәге университетларның берсендә белем алган. Биш телдә иркен сөйләшә. Аның иҗатын мөселман дөньясында нәшидләр башкаруның яңа бер юнәлешен кертүче буларак бәялиләр.

- Яңа альбомымда күтәрелгән төп тема - ул ихласлык. Бүгенге җәмгыятьтә нәкъ менә бер-беребезгә ихласлык күрсәтү җитми. Ислам кешеләрне ихтирамлы булырга чакыра, мин дә үземнең музыкаль әсәрләремдә шуның әһәмиятен искә төшерергә телим, - дип сөйләде Месут Куртис. - Мондый бәйрәмнәр бик кирәк, чөнки җырлар һәм көйләр аша диннәр һәм мәдәниятләр арасындагы бәйләнешләр ныгый.

Концерт азагында чит ил кунаклары тамашачыларга автографлы музыкаль җыентыкларын тәкъдим итте.

***Лилия ГАДЕЛШИНА,***
***intertat.ru***

Дин вә Мәгыйшәт

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27)* .
**Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

Август саны, № 8 (229)

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН;***
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
*Татарстан мөфтие урынбасары* ***Нияз САБИРОВ;***
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ.***

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09614
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **21 нче апрель көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**